КОЛ ШӘРИФ

һәм аның

ЗАМАНЫ

КУЛ ШАРИФ

и его

ВРЕМЯ

КАЗАН l ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ l 2005
КАЗАНЬ l ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО l 2005
УДК 947.0
ББК 63.3 (2 Рос=Тат)
К 52
Китапны әзерләүне һәм бастырып чыгаруны Кол Шәриф мәчете Фонды оештырды
Җаваплы редакторы — Кол Шәриф мәчете Фондының генераль директоры *Марат Сираев*
Җыентыкны тљзүче һәм фәнни редакторлары — филология фәннәре
докторы *Марсель Әхмәтҗанов* һәм ТР информатизация академиясе
әгъза-корреспонденты *Әнәс Хәсәнов*

Книга подготовлена и издана при содействии Фонда мечети Кул Шариф
Ответственный редактор — генеральный директор
Фонда мечети Кул Шариф *Марат Сираев*
Составители сборника и научные редакторы — доктор филологических наук *Марсель Ахметзянов* и член-корреспондент академии
информатизации РТ *Анас Хасанов*

**Коллектив**
Кул Шариф и его время.— Казань: Татарское книжное изд-во. 2005.— 192 с.
ISBN 5–298–04139–6
© Татарское книжное издательство, 2005

## Кереш

## Введение

### Мәчет язмышы – халык язмышы

*Һәрберебезгә мәгълүм, җир йљзендә тормыш шактый кырыс. Кешелек тарихына күз салсак, шул күренә: милләтләрнең, гомумән, халыкларның, уңышлары, шатлыклары кљтелмәгәндә килгән бәла, афәт белән чиратлашып бара... Әйе, тарих кешелек дљньясының бик күп афәтләрен хәтерли. Әмма шунысы күңелдә љмет уята — хакыйкать иртәме-соңмы љстен чыга. Шулай итеп, кешелек тарихының кыйммәтле мирасы яңа буыннар тарафыннан кабат торгызыла, кабат љйрәнелә. Бу китап әлеге хакыйкатьне тагын бер кат исбатлый. Исеменә үк игътибар итик — «Кол Шәриф һәм аның заманы». Татар љчен моннан да кадерлерәк, моннан да мљһимрәк мирасны табуы кыен. Һәм әлеге мирасны безнең буынга кайтарырга насыйп булды. Шунлыктан Кол Шәриф мәчете фондының галимнәребез белән берлектә мондый искиткеч тирән эчтәлекле китапны чыгарырга әзерләве вакытлы һәм әһәмиятле вакыйга дип бәялим. Без хәзерге вакытта халкыбызның иң изге теләкләренең берсе, чынбарлыкка әверелгән тарихи мизгелен кичерәбез — менә Кол Шәриф мәчете сафка баса һәм аның бай мирасы кабат љйрәнелә!*

*Безнең ата-бабаларыбыз дәүләт тотканнар, дљнья халыклары арасында олы дәрәҗә казанып, һәркемнең хокукы сакланган иманлы тормышта яшәгәннәр.*

*Әмма 1552 елның октябрь ае җитә... Әлбәттә, акыл иясе, философ, шагыйрь, дипломат, дин эшлеклесе, үзенең бљтен гомерен, талантын, белемен үз халкының бәхете љчен биргән шәхес —*

*Казан ханлыгының баш имамы Кол Шәриф — халкы ъстенә килгән әлеге афәтнең коточкыч зур булуын күңеле белән сизгәндер. Әйе, дъньяя — кырыс. Бъек остаз да «Угылны атадан аерып, кызын да анадан шулай ук, елатып бер-бер ишектә, зар иттергән дъньяя бу» дип юкка язмагандыр.*

*Әйе, халкыма күп кыенлыклар кичерергә туры килде, әмма ул сыгылмады, бирешмәде. 1552 елгы фаҗигадән соң дистәләгән буыннар алышынды. Инде тел, дин, милләт бетәр сыман тоелды... Әмма Кол Шәриф кебек шәхесләргә ия булган татар халкы түзде, тырышты һәм үсеш-яңарыш башланды.*

*Бүгенге къндә без бердәм булырга тиешбез. Бердәмлек — хәзерге вакытта милләтләр язмышында хәлиткеч фактор. Без моны аңладык һәм бердәмлеккә омтылабыз. Әлеге омтылышның ачык мисалы — Кол Шәриф мәчетенең һәм Благовещение соборының кабат торгызылуы. Кол Шәриф мәчете — татарның берләшү процессын оештыручы үзәк, этәргеч булып тора, без аңа нык-лап тотынырга тиеш. Халкым Кол Шәриф мәчетен торгызу идеясен хуплап алды. Рәхмәт халкыма!*

Татарстан Республикасы Президенты
***Минтимер Шәймиев***

**Резюме**

Во вступительном слове к книге «Кул Шариф и его время» Президент Республики Татарстан М.Ш.Шаймиев подчеркивает своевременность и важность издания книги, посвященной жизни, деятельности и огромной личной роли в истории татарского народа поэта, дипломата, мыслителя и воина Кул Шарифа, чье имя будет носить возрожденная мечеть в Казанском Кремле.

Глава республики выражает уверенность в том, что она будет способствовать консолидации, духовно-нравственному возрождению татарского народа и укреплению стабильности межнациональных и межконфессиональных отношений народов Татарстана.

***Марсель Әхмәтҗанов,***
филология фәннәре докторы

## КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ СОҢГЫ КЪННӘРЕ ҺӘМ СӘЙЕД КОЛ ШӘРИФ

Кем соң ул Кол Шәриф? Ни ъчен аның истәлегенә бәйле рәвештә Казанны нәкъ үзәгендә бер моңарчы күрелмәгән мәһабәт бина калкып чыкты әле?

Һәр халыкның тарихында аның үзенә генә хас, кадерле шәхесләре була. Татар халкының тарихы үзенең үзенчәлеге белән аерылып торды. Аның, күп ъчракта, үз батырлары турында искә алу үтә кыен булды. Гәрчә батырларыбыз бик күп булса... Менә шундыйларның берсе Кол Шәриф: аның халкы ъчен түккән хезмәтләре хакында авыз ачып съйләү мъшкел бер эш иде.Әлеге затның шәхесе, аның Казандагы сигез манаралы мәчете, укытканшәкертләре, язылган әсәрләре хакында борынгыдан калган үтә кыска сәхифәләргә татарның күңел күзе тъшү Кол Шәрифне, аның эшләрен зур итеп ачып, яктыртып җибәрде. Алар түбәндә бәян ителерләр.

Мәскәү урыс кенәзләренең Урта Идел буена инде X гасыр башыннан бирле башланган традицион дошманлык сәясәтен XIV гасырның икенче яртысыннан яңа късч белән башлап җибәрә. Бу агрессив экспансия, 1230 елдан соң бераз тынып торып, Алтын Урда эчендә дәүләт кризисы билгеләре күренү белән, 1367 елда яңадан кузгалып китә. Аның къчен Олуг Мъхәммәд ханның 1438 елда Биләү (Белев) янындагы җиңүе, Мъхәммәд Әмин ханның 1506 елда Казанны алырга килгән 100 меңлек урыс гаскәрен башкала янында тулаем тар-мар китерүе, Сафагәрәй ханның 1548 елга хәтле алып барган оста хәрби хәрәкәте, дипломатиясе, эшчәнлеге дә кыска вакытларга гына туктатып тора ала. Мәскәү гаскәренең 1550 елның февраль аенда Казан янында хурлыклы җиңелүе урыс хъкүмәтенең агрессив асылын үзгәртә алмый. Һәм, ниһаять, Мәскәү кенәзе Иван IV, бътен христиан Европасының теләктәшлегенә, матди һәм техник белгечлә-

ренең хезмәтенә таянып, татар дљньясы берлеген дипломатик уңышлар белән таркатып, Казан ханлыгын яулап алу љчен 150 меңлек гаскәр белән 1552 елның августында яуга чыга.

Казан бу вакытта Нугай Урдасы мирзасы Исмәгыйльнең милли хыянәте аркасында халыкара изоляциядә кала. Аңа каршы дошманлык эшләп Нократ елгасы буендагы татар морзаларының гаскәре дә үз кан кардәшләренең канын түгүгә љлеш кертә. Казан белән Кырымның берләшеп кљчәюеннән курыккан Тљркия дәшми генә Мәскәүнең бу походына фатиха бирә.

Казан халкы Мәскәү кенәзе Иван IV нең бу 1552 елның августында башланган походына каршы 41 кљн буе батырларча кљрәш алып бара. Казан татарлары һәм башкаланың оборонасын оештыручылар яулап алырга килгән баскынчыларның берсүзсез капитуляция ясау турындагы боерыкларына горур рәвештә: «Юк», — дип җавап кайтаралар. Татар батырлары: «Без соңгы тамчы каныбызга кадәр туган йортыбызны саклап сугышырбыз, ләкин кол булмабыз», — дип, горур җавап бирәләр. Әлбәттә, татарларның хәлен Камай морзаның су юлларын күрсәтеп шартлаттыруы һәм Япанчы атлы гаскәрләрен Явыш морза хыянәте белән туздырылуы авырайта. Ләкин куркып тез чүгәргә торучылар артык күренми.

Тигезсез сугышта, 1552 елның 2 октябрендә, Казан каласы алынып, җимерелә, яндырыла, талана. Урыслар берәүгә дә шәфкать күрсәтмиләр, шәһәр мәетләр белән тула. Татарларның батырларча кљрәшен хәтта урыс кенәзе Андрей Курбский да югары бәяли.

Иван IV гаскәре баштан ук Казанны талап баерга килгән. Казанны алганда талау эше — мародерлык белән мавыгып киткән урысларны шәһәр эчендә татарлар кыра башлыйлар, ләкин сан ягыннан тигезсезлек урыс файдасына була. Казанны яклау юлында оборона җитәкчелегенең рухы булган Кол Шәриф сәйед тә соңгы чиктә үз шәкертләре белән сугыш мәйданына чыга һәм фидакарьләрчә кљрәшеп һәлак була. Казан үзәгендә, хан сарае янында, аның исеме белән аталган мәһабәт, күп манаралы мәчет бинасы да, батырларча үлгән сәйеднең һәлакәте шаһиде булып, ярым җимерек хәлгә килә.

Күренекле татар тарихчысы, мәгърифәтче галим, дин эшлеклесе Шиһабетдин Мәрҗанинең язуына караганда, Казандагы хан сарае янында сигез манаралы мәчет була. Мәчетнең имамы булып Казан ханлыгының сәйеде, галим, шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Кол Шәриф Мансур сәйед улы Хаҗитархани торган. Моннан 450 ел элек күп манаралы легендар Кол Шәриф мәчете башкаланы — Казанны бизәп торган. Ул үзенең зиннәтлелеге, мәһабәтлеге, гүзәллеге, бай китапханәсе белән татар халкын таң калдырган. Ул татар дљньясында, Бакчасарайдагы Зынҗырлы мәдрәсәсеннән соң икенче бер мәгърифәт үзәге, үзенә бер академия булып шљһрәт алган, шуңа күрә аның даны XXI гасыргача татар арасында онытылмаган. Соңгы имамының эшчәнлеге, гыйлем-мәгърифәт чәчүе сәбәпле, бу мәчет-мәдрәсәгә Кол Шәриф исеме тарихның үзе тарафыннан бирелгән.

Кол Шәрифнең истәлеге татар халкы тарихына алтын хәрефләр белән язылган. Ул тарихи шәхес, халык күңеленә үзенең илһамлы, рухи бљеклеккә љндәгән поэтик әсәрләре белән дә мәңгелек урын били. Аның шигырьләренең сакланып калган хәтле љлешен татар китап күчерүчеләре, «Бакырган китабы» исемле шигъри антологиягә туплап, кулъязма китаплар рәвешендә дә халыкка җиткергәннәр. Бу китаплар һәм аның авторы турында үз вакытында татар галимнәре Г.Газиз, Г.Рәхим һәм М.Галиләр фикерләрен язып калдырганнар.

Шагыйрьнең әсәрләре соңгы елларда М.Әхмәтҗанов, Ф.Хәкимҗанов, Ә.Шәрипов, Җ.Зәйнуллиннар тарафыннан «Идел», «Гасырлар авазы», «Аргамак», «Сљембикә» журналларында, «Ватаным Татарстан» газетасында һәм шулай ук «Татар поэзиясе антологиясе»ндә басылдылар. 1997 елда, Кол Шәриф иҗатына нисбәтле дип саналган әсәрләрне туплап, әдәбиятчы Ә.Шәрипов шагыйрьнең «И күңел, бу дљньядыр...» исемле беренче җыентыгын Казанда тљзеп чыгарды.

Кол Шәриф, күренекле дәүләт эшлеклесе, дипломат буларак, урыс елъязмаларында берничә мәртәбә искә алына.

Хаҗитархан ханлыгында сәйед булып торган әтисе Мансур сәйед үзенең улы Мљхәммәт Шәрифне (шул ук Кол Шәриф) Казанга җибәрә. Киң белемле, әхлакый саф һәм намуслы бу кеше анда тиз арада абруй казана. Ул, ак атка атланып, шәһәр буйлап йљрергә яраткан. Казанлылар аңа хљрмәт йљзеннән каршысында бил бљгеп сәламли торган булалар. Хәтта Сафагәрәй дә, аның белән очрашканда, атыннан тљшеп, аның чапан итәген үбеп, сәламәтлек теләп киткән.

Кол Шәрифнең абруе Казанга күрше булган дәүләтләрдә дә танылган. Аны Кырымда да, Тљркиядә дә, Мәскәүдә дә яхшы белгәннәр. Бу җәһәттән Шиһабетдин Мәрҗанинең фикерләре игътибарга лаек: урыс кенәзләре, Казан ханнары белән элемтәдә торганда, аңа махсус хатлар, шулай ук бүләкләр юллый торган булалар.

Аның фаҗигале үлем тарихы да урыс язма чыганакларында теркәлеп калына. Кол Шәриф, Казанны саклаучыларның соңгылары рәтендә, үзенең бер тљркем шәкертләре белән шәһидләр хисабыннан һәлак була.

Казан тарихын гадел позициядән торып махсус љйрәнгән тарихчы-галим Михаил Худяковның дљрес билгеләп үткәненчә, Кол Шәриф дәүләтнең иң мәртәбәле дин башлыгы итеп танылa. Ул дәүләттә беренче шәхесләрдән саналган һәм ханнар алышынган вакытта үзенең югары хәле аркасында вакытлы хљкүмәтләрне җитәкләгән. Кол Шәриф шулай ук илче (дипломат) йомышларын да үтәп йљри. Илче булу аңардан киң белем, зирәклек, тирән акыл, зур дәүләт сәясәте белгече булуны таләп иткән (Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. — Казань, 1923. — С. 152).

Торгынлык чорлары үтеп, инде демократия җәелеп киткән вазгыять шартларында җәмәгатьчелек Кол Шәриф мәчетен торгызу мәсьәләсен күтәрде. Татар халкының гасырлар буе килгән хыялын гамәлгә ашыру максатында Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиев 1995 елның ноябрендә Кол Шәриф мәчетен торгызу турындагы Указга кул куйды.

Бљтендљнья шәһәр тљзелеше практикасында турыдан-туры охшашы, тиңдәше булмаган мондый зур дини-иҗтимагый ансамбльне тљзү архитекторлардан һәм тљзүче-инженерлардан һљнәри сәләт кенә түгел, ислам мәдәнияте буенча кирәкле белемнәргә ия булу шартын да таләп итә. Кол Шәриф һәм Казанны саклаучылар истәлегенә багышланган яңа мәчет бинасы, татар халкының милли һәм дини йолаларын торгызу символы булган тарихи һәм мәгънәви корылма истәлеге буларак, газиз Ватаныбызның, ата-бабаларыбызның хәләл каннары түгелгән туфракта калкып чыкты. Кол Шәриф мәчете ул Казан ханлыгына гына түгел, бљтен татар мәдәниятенә салынган шанлы һәйкәл булып гасырлар аша кичәр.

**Резюме**

Статья доктора филологических наук М.И.Ахметзянова посвящена описанию событий осени 1552 года (завоевание Казани) характеристике личности сеида, поэта и дипломата Кул Шарифа, его роли как защитника интересов татар.

***Дамир Исхаков,***

доктор исторических наук

## Воин, поэт и мыслитель Кул Шариф

Широкую известность Кул Шарифа в последний период существования Казанского ханства подтверждают многие исторические источники, а также сведения, сохранившиеся в народной памяти и обобщенные Шигабутдином Марджани. Опираясь на них, можно утверждать, что Кул Шариф в ханстве накануне его падения являлся главой мусульманского духовенства, верховным сеидом. Андрей Курбский, описывая эпизод, связанный со взятием русским войском Казани в 1552 году, называет его на европейский лад «великим бискупом», то есть епископом, и добавляет, что сами татары считают Кул Шарифа «великим анарыи», или «амиром».

Слово «амир» переводится с арабского как «повелитель», или «руководитель». А вот в первом случае Курбский явно использовал латынь: «honor» — честь, почет, почесть или «honorus» — почетный, уважаемый. Похоже, что эти выражения применены им для перевода титула верховного сеида, который, по замечанию Марджани, звучал как «накыйбел-ашраф» — «руководитель великих».

Как известно, сеидами в мусульманском мире называли потомков пророка Мухаммада из ветви, восходящей к его внуку Хусейну. Очевидно, и Кул Шариф, будучи сеидом по происхождению, возводил свой род к Мухаммаду. Недавно обнаруженная и опубликованная литературоведом М.И.Ахметзяновым генеалогия сеидов Шакуловых из Касимовского ханства показывает, что она действительно через многие поколения восходит к Хусейну и Мухаммаду. Следовательно, причастность Кул Шарифа по рождению к сеидам была не вымышленной, а реальной.

В XV — XVI веках в каждом отдельном татарском ханстве могло быть несколько сеидов, лишь один из которых являлся верховным (С.Герберштейн, автор «Записок о московитских делах», отмечает наличие в Казанском ханстве «верховного жреца»). В Казанском ханстве такой сеид, как видно из жалованной грамоты хана Сахиб-Гирея 1523 года, именовался «судат-гызам» (садати-гозам), что переводится как «великий сеид». Есть основания полагать, что Кул Шариф верховным (великим) сеидом в государстве стал в октябре 1551 года после казни ханом Шах-Али прежнего верховного сеида Кул Мухаммада*. К тому времени Кул Шариф был уже известным государственным деятелем, о чем говорит его присутствие среди знати ханства, присягавшей на верность хану Шах-Али 14 августа 1551 года в Свияжской крепости.

Судя по тому, что нам известно, Кул Шариф, как и его предшественник Кул Мухаммад, был из рода крымских сеидов. Некоторое время он жил в Астраханском ханстве вместе с сеидом Мансуром, предположительно своим отцом. Отсюда у него тахаллус «Хаджитархани». М.И.Ахметзянов, опираясь на эти и другие сведения, выдвинул обоснованную гипотезу, что автором сочинений периода Казанского ханства — «Зафername-и вилайет-и Казан» (1550 г.) и стихов-мунаджатов — в первом случае названным «Шарифом Хаджитархани», во втором — «Кул Шарифом» — является сеид Кул Шариф. Действительно, Кул Шарифа даже после того, как он стал верховным сеидом, русские источники продолжали именовать «муллой». Не высокая ли образованность его так отражалась в летописях? Наверное, да. В то же время из «Зафername-и вилайет-и Казан» отчетливо видно, что его автор был весьма образованным человеком, обладавшим знаниями в области астрономии, истории (не только татарской, но и русской), государственных дел. Кроме того, в этом произведении, написанном в целом прозой, довольно много поэтических строк. Одним словом, Кул Шариф (он же Шариф Хаджитархани) был и поэтом.

Эпоха, в которой жил сеид Кул Шариф, — это трагическое время движения Казанского ханства к своей гибели. Автор «Зафername-и вилайет-и Казан» оставил потрясающие строки, описывающие трагедию своего народа. Он говорит о Казани: «Ей неоткуда ждать помощи и поддержки, кроме покровительства Тенгри и помощи ангелов. Из-за такой тяжелой ситуации падишахи города Казани обеспечивают безопасность своего государства путем соглашения со страной кяфиров. Было так: для благополучия народа и ради его жизни заключали договор с Москвой, между двумя сторонами ходили послы, обеспечивая взаимопонимание». Это было написано в 1550 году, но уже в апреле 1551 года началось новое наступление русских войск, которые в июне обступили Казань. Настали тяжелые времена, и казанцы дрогнули: они послали «к Шигалею и к воеводам бити челом, чтобы государь пожаловал, гнев свой им отдал, а пленети их не велел, а дал бы им на государство царя Шигалея, а Утемешь-Гирея царя государь к собе взял и с материю Сююнбика-царицею» (Патриаршая летопись). С таким предложением к хану Шах-Али и русским воеводам приезжали «мулла» Кул Шариф и тюменский «князь» Бибарс Растов. Но они действовали не самостоятельно, а выполняли волю «всей земли Казанской», что отчетливо видно из грамоты казанцев, отправленной тогда Ивану IV. Кроме того, послы не сразу приняли условия Москвы — в летописном сообщении от 9 августа 1551 года говорится о том, что во время переговоров они «во многом заперлися», то есть не соглашались. Хронист дальше пишет о татарах: «обычай бо их бяше изначала лукавьствовати». Заставить казанцев принять столь тяжелые условия можно было лишь силой. И завоеватели пригрозили: если казанцы «не учинять на государеве воле... на ту же осень... государь... хочет ратию съ всеми людми». Лишь после таких угроз послы приняли условия Москвы, среди которых было и требование выдать Сююмбике с сыном. Ясно, что никакой личной вины у Кул Шарифа с «князем» Бибарсом в этом не было — они выполняли общегосударственное решение, да и то всего лишь как дипломаты.

Верховный сеид Кул Шариф погиб при взятии Казани русскими в 1552 году. Марджани, опираясь на народные предания, сообщает, что Кул Шариф со своими последователями, объединенными в особое военное подразделение — «полк», состоявший из молодых дервишей и суфиев, оборонялся отступая, вплоть до здания медресе, потом поднялся на его крышу, где был заколот, и упал вниз. Так трагически прервалась жизнь этой выдающейся личности эпохи Казанского ханства.

В «Зафername-и вилайет-и Казан» есть такие строки:

О, Шарифи, если ты еще надеешься на лучшее,
Не уходи с этой земли,
Ибо если ты уйдешь, кто же будет сахибом
города Казани?

Нет, великий сеид, поэт и мыслитель Кул Шариф не ушел из Казани, названной им «явлением времени». Повинуясь духу новой эпохи, он возрождается в Казанском Кремле в облике мечети, носящей его имя. Вскоре, надеюсь, это имя будет носить и одна из центральных улиц столицы Татарстана.

**Резюме**

Тарих фәннәре докторы Дамир Исхаков үзенең мәкаләсендә Кол Шәрифнең күпкырлы талант иясе булуын сурәтли. Әлеге язмадан аңлашылганча, Кол Шәриф — курку белмәс къэрәшче дә, халык арасында их-

тирам казанган имам да, күренекле шагыйрь дә. Автор Кол Шәрифне дипломат буларак та ача һәм бу уңайдан шул чорның гыйбрәтле вакыйгаларын тасвирлап уза.

***Әнвәр Шәрипов,***

филология фәннәре докторы

## Кол Шәрифнең тормыш юлы

Кол Шәриф... Бу исем татар халкының бәйсезлек љчен кљрәше тарихына алтын хәрефләр белән язып куелган. Кол Шәриф дигәндә, безнең күз алдына блтен гомерен, талантын, тырышлыгын һәм ахыр чиктә газиз җанын да үз халкының азатлыгы љчен изге кљрәшкә биргән мәһабәт озын буйлы, ак сакаллы, горур бер акыл иясе, шагыйрь, дипломат һәм дин эшлеклесе, Казан ханлыгының иң күренекле имамнарының берсе килеп баса.

Кол Шәриф турында без нәрсәләр беләбез соң?

Аның турындагы тарихи мәгълүматлар аз сакланып калган. Сакланганнары да љзек-љзек кенә.

Кол Шәриф — Казан ханлыгы тарихында күренекле роль уйнаган шәхес. Ул начар даны белән атаклы Шаһгалигә 1546 елда кискен каршы чыккан Мансур сәеднең улы була. Кол Шәриф, яшьтән үк күңеленә иман нуры сеңдереп, әтисенең шифалы йогынтысында тәрбияләнеп үсә. Тиздән ул саф әхлаклы һәм тирән белемле укымышлы булып җитешә һәм аны 1546 елда, әтисе Мансур үлгәннән соң, Казан ханлыгы руханиларының башлыгы, ягъни баш имам итеп билгелиләр. Шул вакыттан алып ул Казан ханлыгында яшәгән безнең ерак әби-бабаларыбызның ислам тәгълиматын үзләштереп, шәригать кануннарын үтәп, күңелләрен иман нуры белән нурландырып яшәүләре љчен, аларны әхлаклы, иманлы юлга — изге юлга кертү љчен зур тырышлыклар куеп яши. Һәм, әлбәттә, үзе дә тормышта Казан халкы љчен әдәп-әхлак үрнәге, белемлелек љлгесе булып саналган. Аның халык арасындагы абруе гаять зур була. Аны үзе яшәгән патшалыкта гына түгел, чит мәмләкәтләрдә дә бик ихтирам иткәннәр. Бу олы ихтирам, хљрмәт хисе гасырлар буена, ничәмә-ничә буыннар алышынса да, халкыбыз күңелендә югалмыйча сакланып килгән; ул хис, риваять-легендаларга әверелеп, әле бүген дә халкыбыз хәтерендә яшәп килә.

Кол Шәриф үз заманының күренекле дипломаты да булган, Казан ханлыгы љчен авыр елларда халык мәнфәгате љчен кљрәшкән. Рус елъязмаларында, мәсәлән, Кол Шәриф Казан белән Мәскәү арасында барган катлаулы дипломатия эшләрендә дәрәҗәле җитәкче буларак телгә алына. Мәсәлән, 1551 елның җәендә ул Казаннан Зљя кальгасына җибәрелгән илчелеккә җитәкчелек итә һәм Зљядә Казан тәхетенә утырырга љметләнеп кљтеп торучы Шаһгали белән бик җитди сљйләшүләр алып бара. Шул ук елның 14 августында урысларның, Казан хљкүмәтенә әйтеп тә тормастан, Казан ханлыгының Тау ягын үзенә кушуы турындагы мәсьәләне тикшерүгә багышланган Корылтайда, үз туган илен яклап, ялкынлы чыгышлар ясый. Тәхеткә Ядегәр Мљхәммәд хан утыргач, Кол Шәриф хљкүмәт составына кертелә һәм Казан ханлыгының кљндәлек эшләрендә дә актив катнаша башлый. Явыз Иван да, 1552 елда Зљя кальгасына килгәч, Казан кешеләренә багышланган мљрәҗәгатен Кол Шәриф исеменә күндерә.

Тарихи хезмәтләрдә сакланып калган менә шундый љзек-љзек кенә мәгълүматлар да безгә аның үз туган иленең чын ватанпәрвәре булуы, күренекле, олы дәрәҗәле бер шәхес булганлыгы турында сљйлиләр.

Кол Шәрифнең үлеме дә чын батырларча-каһарманнарча булган. Ул, үз Ватанын, Казанның мљстәкыйльлеген, үзенең һәм халкының иманын саклап калу љчен, чын мәгънәсендә соңгы тамчы канына чаклы кљрәшеп һәлак була. Халкыбыз тарихындагы иң авыр кљннәрдә, 1552 елның 2 октябрендәге рус гаскәрләре һљҗүме вакытында, ул Казан Кремлендә барган бәрелештә җитәкчелек итә: кулына кылыч-калкан алып, иң алгы рәтләрдә сугыша. Рус гаскәрләренә иң нык һәм иң соңгы каршылык күрсәтүчеләр дә Кол Шәриф җитәкчелегендәге шәкертләр һәм муллалар тљркеме була. Ул шунда батырларча һәлак була! Рус гаскәрләре Казан Кремленә ханлыкның баш сәеде Кол Шәрифнең үле гәүдәсе аркылы атлап кына бәреп керә алалар. Әйе, бу бары тик әкиятләрдә генә сљйләнелә, җырларда гына җырлана торган батырлык! Һәм халкыбыз Кол Шәрифнең бу батырлыгын гасырлар буена онытмады, күңелендә саклады; ул киләчәктә дә онытылмас! Халкыбыз Кол Шәрифне изге сугышта корбан булган изге җаннар-шәһитләр исемлегенә кертте...

Халкыбызда Кол Шәрифкә булган ихтирам әле бүген дә чиксез. Мәсәлән, башкалабыз Казанның иң үзәк урамнарының берсенә халкыбыз Кол Шәриф исеме бирелүен кљтә. Ханлык дәверендә Казан Кремлендәге иң зур җәмигъ мәчет — Кол Шәриф мәчете дип йљртелгән. Җәмәгатьчелек шул мәчетне яңадан торгызу, яңадан салу мәсьәләсен күтәреп чыкты. Аңа нигез салынды инде. Соңгы елларда Кол Шәриф рухына багышлап Коръән чыгулар, җәмәгать намазлары укулар ешрак үткәрелә башлады. Язучыларыбыз,

шагыйрьләребез Кол Шәрифкә багышлап әсәрләр иҗат иттеләр һәм хәзер дә иҗат итеп киләләр; аның образы шигырь-поэмаларда, тарихи романнарда чагылыш тапты. Ә киләчәктә Кол Шәриф образы сәнгатьнең башка търләрендә дә — музыка, рәсем, кино сәнгатьләрендә дә, опера-балетларда да үзенең лаеклы чагылышын табар әле. Болары алда әле...

Кол Шәриф иҗаты моңа кадәр бътенләй диярлек билгеле түгел иде. Аның турында фәнни хезмәтләр дә язылмады. Кол Шәрифнең безнең къннәргә биш шигыре һәм «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» әсәре генә килеп җиткән. Кол Шәрифнең бътен иҗат мирасы шулардан гына тормаган. Әле алар табылачак.

Кол Шәриф барыннан да элек — суфи шагыйрь. Ул үзенең остазлары итеп урта гасырлар търкu поэзиясендә мәшһүр суфи шагыйрьләр Хуҗа Әхмәт Ясәвине һәм аның шәкерте Съләйман Бакырганины саный.

Кол Шәриф безгә мәгълүм шигырьләрендә Аллаһ каршына гъناһсыз бару идеяләрен пропагандалый; аның әсәрләре укучыларны, гамьсезлек йокысыннан уянып, Аллаһны олыларга, гомереңне гыйбадәт кыйлып үткәрергә, дъньяда мәңге калырмын дип алданмаска, Коръән аятьләрендә әйтелгәнчә яшәргә, гънаһларың ъчен Аллаһтан ярлыкау сорарга чакыра. Алар — мәхәббәт шигырьләре. Ләкин алардагы мәхәббәт ул Аллаһка мәхәббәт, күңелне Аллаһка юнәлтеп яшәүне аңлата.

**Резюме**

Автор статьи ведет речь о тех немногих исторических сведениях, которые имеются относительно личности Кул Шарифа. Но даже эта ограниченная информация свидетельствует о той огромной государственной роли, которую он играл. Свою жизнь до последнего вздоха Кул Шариф посвятил своему народу, и народ не забыл его.

Кол Шәриф әсәрләре

## ЗАФӘРНАМӘ-И ВИЛАЯТЕ КАЗАН
## ПОБЕДА КАЗАНСКОЙ СТРАНЫ

Болгар вилаяте, риазият (математика) китапларында әйтелгәнчә, җиде икълимнең (климатның) җиденче икълимендә[1], ай тәрбиясендәдер һәм айның яклавындадыр, янә бу Болгар вилаяте Тъньяк котыпка бик якын түгел дип хисаплана. Җәүзә (май) йолдызыннан соң һәм Сәрәтан (июнь) йолдызының башында биш вакыт намазның берсенең — ясигъ намазының[2] үтәлү вакыты калмас, чънки ике имам (ягъни Имам Мъхәммәд[3] һәм Йосыф[4]) карашында шәфәкъ кызыллыгы, югалып китмәстән, бераз элегрәк хасыйль булган кызыллыктан гыйбарәттер.

Бу таң беленмәстән әүвәл үтәлергә тиешле намаз вакытында тулы таң вакыты килеп җитәр һәм моннан соң бу халыкка ясигъ намазын үтәү тиеш түгел. Мәсьәлә аерым алганда «Әл-Кенз», «Әл-Вафи», «Әл-Кафи» китапларында каралган кебек хәл ителә. (Әлеге китапларның авторы Хафизетдин бине Бәрәкәт әл-Нәсифи, 1310 елда үлгән. Аның китапларының тулы исемнәре: «Кенз үл-Дакайык», «Әл-Вафи фил форуг», «Әл-Кафи».)

Бу Болгар вилаятенең пайтәхете булган Казан, заманының елъязмаларыннан күренгәнчә, искедән бер мъселман шәһәре булган. Казан мъселман ълкәләреннән еракта һәм кяфер ълкәсенә чиктәш урнашкан.

### МИСРАГ

Һичкем яманның күршесендә булмасын!

*(Фарсычадан тәрҗемә)*

Казанга һичбер җирдән ярдәм һәм таяныч ирешмәс, бары тик Тәңре якын һәм фәрештәләр ярдәмче. Шушы авыр сәбәптән Казан шәһәренең падишалары кяфер иле (ягъни Мәскәү) белән килешүләре аркылы мәмләкәтләренең җитешлеген тәэмин итәләр. Халкының рәхәте һәм яшәеше ъчен Мәскәү белән солых булып, ике арада илчеләр йърешер, аңлашып һәм барышып-килешеп йърмәктә иделәр.

### ШИГЫРЬ

Тәртип ике яклыдыр, һәм ул ике сүздә аңлатыла:
Дусларга гайрәт һәм дошманнар белән
барып йърешмәк.

*(Фарсычадан юлдан-юл тәрҗемә)*

Инде башка яктан, кылыч һәм каләм сахибе (ягъни куркусыз бер гаскәр башлыгы вә яхшы бер язучы булган) асыл нәселле, затлылык чишмәсе, Тәңренең рәхмәтенә тиенгән, Тәңре ярлыкавын алган Әбелгази Сафагәрәй Баһадир хан[5], Казан љлкәсенә падишаһ булгач, кяферләр аның бу дљньядагы дине һәм ахирәттәге йорты җиреннән аерылмаслыгы нәтиҗәсендә, озак заманнар һәм күп вакытлар шулай кичте.

*(Коръән, Ниса сүрәсе, 78 нче аять)*[6]

«Кайда гына булсагыз да, үлемнән котыла алмассыз. Адәмнәр яхшылыкка очрасалар, бу—Аллаһдан булган эш, диләр, яманлыкка тарсалар, бу —синнән, диләр. Син ул адәмнәргә әйт, яманлык та Аллаһдан, диген. Нигә алар моның шулай икәнен аңлый алмыйлар икән?»

...Кяферләр* (ягъни Мәскәүләр) булып узган бу вакыйгага шатландылар. Дљньяның бу авыр вакыйгасына сљенеч тоеп, ул (ягъни Куркыныч Иван) денсез кяфер, тәкәббер, кинәле, ямьле кљннәрне бозучы, дљньяга фетнә салучы ике шайтанның бере иде. Үзенең мәлгунь гаскәрен, — тавышлары Фиргавен Нәмруд[7] сурәтле,—имансыз Иван[8], башта булган бљтен гаскәре, сансыз туплары, тљфәңнәре, чама белән сигез йљз меңлек гаскәре белән килеп, Казан шәһәренең әйләнә-тирәсен сарып-чолгап алдылар.

Кяферләрнең гаскәре кырмыска һәм саранчалардан да аз түгел иде. Алар, Яҗүҗ һәм Мәҗүҗ нәселеннән булып, Адәм нәселеннән түгелләр иде.

**ГАЗӘЛ**

Гаҗәйеб бер җай-гыйшрәттер җиһанда бу Казан шәһре,
Моның тик булмагай галәмдә, борадәр, әл-Аман шәһре,
Казан тик шәһри мәгъмур бителмәс дљньяда һәргиз,
Казандин аш эчәдерләр, ничаклы бу җиһан шәһре.
Бу бер милке ирдер калмыш абаэ ган җид ханлардин.
Ирер бу йир һәмишә дљньяда хан бине хан шәһре.
Йирен-йортын сатып бирмәс атасының ясакыны,
Ничек килгән ушал мәлгунь, имәсдер бу Ибан шәһре,
Шәрифи, китмә бу йирдин, газа љмидегәр булса,
Бу кљндин соң дигәйләр кем, будыр сахиб Казан шәһре**.

Казан шәһәренең кала капкасының берендә бу мәмләкәтнең (ягъни Казан иленең) терәге, бу љлкә инсаннарының юл күрсәтүчесе мәрхүм Пулат бәкнең[9] углы Мамай бәк белән Нургали мирза[10] — кадере арткан ир, сугыш азманы (тәҗрибә иясе) һәм егетләр љлкәне — Дара һәм Искәндәр[11] кебек егетләрне җыеп, каршысында торыр иде… Тагын Хан Морҗалыйдагы[12] кала капкасында баһадирлык мәйданының сафдары, егетлек сәнгатенең арысланы Кузыйчак углан, кадере артсын... Тагын бер кала капкасында егетләр башлыгы, баһадирлык мәйданының Искәндәре Акмљхәммәт углан[13], гомре озын булсын… Тагын бер капкада пәйгамбәребез нәселеннән Сәйед ата оныгы, мәрхүм һәм мәгъфүр (ярлыканган) сәйеднең углы Кол Мљхәммәд сәйед[14] — бљеклеге дәвам итсен — башлап яшь дәрвишләрне һәм суфиларны туплап, газа (изге сугыш) атына атланып, янә сугышка чыныктырып, сугыш киемнәре киеп, кяфергә каршы хәзерләү һәм караудa иде.

Тагын бер капкада Дара һәм Искәндәр кебек, Рљстәмгә[15] тиң һәм Баһрамга[16] тиңдәш Барбулсын аталык[17]... үз капкасында коллары белән торыр иде.

Тагын башка бер капкада шәһәрнең (ягъни Казанның) бәге һәм Болгар љлкәсенең хакиме, солтаннарның күз карасы, хљрмәт һәм бљеклек энҗесе, ханның хәзинә капкаларын ачкан Бибарс[18] бәкнең гайрәте артсын, баһадирлык гайрәте хәрәкәткә килеп, егетлек йљрәге тибрәнеп, һәр заман диер иде кем...

Ат казанган башка егет һәм бәхет иясе баһадир кемсәләр: Тарихи бәк, һәм Айкилде бәк, һәм Акымтай бәк һәм башка җәмәгать хаҗилар — Тәңре аларның һәр йирдә ярдәмчесе булсын — бер йирдә кяферләр хыянәтчел һљҗүм башласалар, ул йиргә үзләрен йиткереп, җан һәм тел белән кљч һәм ярдәм биреп, явыз кяфер белән сугышып һәм үтереп, кяферләрне җиңеп, сљңгеләрен сындырып, җиңүче хљрмәтенә лаек булдылар.

Кыскасы, ике гаскәр, бер-беренә ташланмак љчен, үзара кара-каршы килгәннәр иде[19], һәммәсе, дљрес булган сүзләргә караганда, кяфернең гаскәрендә унбер утлы туп саналды. Бер яхшы тупчы качып килеп әйткән хәбәр. Ул тупларның һәрбер утлы ядрәсе чама белән Казан ташының бер батманы кадәр бар. Зурлыгы ат тубрасы чаклы күренде. Ул ядрә эчендә тљрле тылсым һәм бертљрле тәртип тљрле эшләр кылыр иделәр. Әфләтун[20], гаклы хәйран калып, Аристу[21], зиһене хәйран булып, башы әйләнеп китәр иде. Ул ядрәләрне, тыштан тимерләр белән коршап, җизләр белән чүкеп, эченә ак нефть куеп, күкертләр салып, кечкенә тљфәңчеләр дљресләп, эченә кургашыннан дүрт-биш ядрәләр салып, беркетеп, бәйләп, чыдамлы һәм нык кылып, караңгы тљннәрдә атар иделәр. Күргән кешеләр күктән йолдызлар һәм планеталар тљшә дип

уйладылар. Ул утлы ядрәләрдән чәчрәп чыккан һавадагы очкыннарны күргән кешеләр күкләрдәге йолдыз һәм планеталар һәммәсе дә йиргә тљште, дип санар иделәр[22].

Ул утлы ядрәләр кичләрдә шәһәр эчендә һәр йиргә тљшәр иде, һичкемнең ул утлы ядрәне барып сүндерергә дәрманы булмады.

**БӘЕТ**

Гәрчә һәр утны килеп сүндерсә булгай су коеп,
Буйлалыг* утны ки һәм су берлә булмас сүндереп.

Ләкин кайбер яшьләр һәм гайрәтле егетләр ул утка үзләрен чаяннар кебек атарлар, аны сүндерерләр, һәм аның әсәре вә эзе дә калмас иде.

**ШИГЫРЬ**

Суга балык, утка сәмәндәр кирәк,
Иш кљнендә мәрд-диләвәр кирәк.
Ич кешегә һиммәт әгәр булса яр,
Гакыйбәтел-әмер морадын табар.*

Тагын дүрт-биш һавалы туплары бар иде, һәрбер ядрә ташы бер тау кисәгенә тиң булды. Ул туплар һәрвакыт атып тордылар. Бу туплар атылса, ядрә ташы, хәрәкәт куәте белән кош кебек очып, һавага яннан чыгар, югарыда бер ноктага җитеп, асманда (һавада) йљреп хәрәкәт куәте беткәч, соңра табигый рәвештә түбәнгә тљшәр иде, каза һәм тәкъдир угыннан тизрәк тљшәр.

**ШИГЫРЬ**

Югарыдан бер каза тљшмәсен,
Түбәндәгеләр һәммәсе сукыр калыр.
*(Фарсычадан юлга-юл тәрҗемә)*

…кыскасы ике гаскәр, тимергә чолганып, бер-берсенә каршы торып, сугыш һәм кљрәш белән мәшгуль булдылар.

**МИСРАГ**

Ак тикин гауга ирде, гүя мәхшәр,
Чигәчәң хәнҗәр бик ярдин рәсид,
Зи шәһре Казан хун биҗәйхун рәшд.

(Шундый гауга иде ки, гүя мәхшәр,
Хәнҗәр чыңы бар мәйданны каплады,
Казан шәһәрендә кан Әму-Дәрьядай акты.)

Аллаһның ярдәменә, Ислам һәм пәйгамбәренә мактау һәм сәламнәр булсын, Аллаһның ярдәме, галәмне яраткан Тәңренең булышлыгы, фәрештәләрнең якынлыгы ярдәмче булган һәм хљрмәтле аятьтә әйтелгән авазы мљселманнарның колакларына килеп җитте һәм аятьтәге «Әгәр Аллаһ сезгә ярдәм итсә, үзегезне һичкем җиңә алмас» (Коръән, III сүрә, 160 нче аять һәм IX сүрә, 25 нче аять) дигәннәрнең мәгънәсе расланды. Бәхете кара һәм җиңелгән дошманны казанлылар шулкадәр кырдылар ки, «аларның барлык эзләре җир йљзеннән агып китте» (Коръән, VI сүрә, 45 нче аять). Тәңре явыз кавемне соңгы кешесенә кадәр юк итте, Тәңрегә мең шљкер булсын. Каланың ике тарафында кара кяфер үлесе кылыч һәм хәнҗәр ризыгы, кортларга ризык булып ятырлар иде. Аяк басарлык та җир калмады.

Кыскасы, моның кебек бәрелешләр уналты кичә һәм кљндез туктаусыз љзелмичә дәвам итте. Унберенче кљнне* рухы тљшкән кяфер кире ташланды һәм каһәрләнеп чигенде.

**КЫЙТГА**

Сакласа һәркемне дошмандин Ходай, ләм-йәзил
Хаҗәт ирмәсдер аңа кимәк зәррә гали хисар.
Сакламас булса такы (юк) бу икәүдин мәнфәгать,
Сакласа, мљмкин имәс бер кылны кисмәк зљлфљкар**.

Шљбһәсез Аллаһдан үтенеп, һәм юмартлык иясеннән љметләнүем шулдыр ки, һәр урында бу «Зафәрнамә-и...», дәүләт ияләренең игътибарлы карашларына туры килсә, — бу фәкыйрь кем гаебледер, гаҗиз һәм кимчелегенә үкенүчедер, — гљнаһ һәм ризасызлык белән аның морадына үкенү һәм ихлассызлык фатихасы кылмасыннар. Рәхимле Аллаһның сүзе белән: Амин.

Ошбу вакыйга мљхәррәм аенда, тугыз йљз илле җиденче елда[23] булды, һәм бу язу һәм акка күчерелгән сәхифәләр каргалган колларның иң фәкыйре Шәриф Хаҗитарханинныкыдыр.

## ИСКӘРМӘЛӘР

Зәки Вәлиди текстны басарга әзерләгәндә нык кыскарткан. Күп нокталар кыскартуларны аңлата.

1 Мљселман географик традициясе буенча җир йљзе җиде климатка бүленгән. Һәр климатның язмышында күк йљзендәге җисемнәрнең катнашы барлыгына ышанганнар. Ел тәүлеге кояш календаре буенча унике йолдызлыкка бүленгән (җәүзә, сәрәтан, сәвер һ.б.).

2 Ясигъ намазын Идел буенда кљн озынлыгы 17 сәгатькә җиткән айда уку мљмкин булмый, чљнки ул офыкта шәфәкъ югалгач кына укылырга тиешле намаз була. Бу мәсьәләдә бәхәс Шиһабетдин Мәрҗани һәм Муса Бигиевләр заманына кадәр килә һәм алар тарафыннан чишелеш таба. Монда хәлиткеч урынны Шиһабетдин Мәрҗанинең гарәп телендә язылган «Нәзуратель-хак» әсәре били.

3 Имам Мљхәммәд бине Идрис әл-Шәфигый, руми 820 елда үлгән мљселман юристы.

4 Йосыф — Әбү Йосыф, руми 798 елда үлгән мљселман юристы.

5 Казанда 1524 — 1532, 1535 — 1546, 1546 — 1549 елларда идарә иткән хан Сафагәрәй Фәтехгәрәй углы. Ул 1549 елның мартында 42 яшендә Казанда, үз сараенда серле шартларда һәлак була. Сљембикә манарасы алдындагы мәйданга җирләнә. Аның табуты 1977 елгы археологик казулар вакытында Сљембикә манарасы янында табылды. (Кара: Археологические открытия 1977 года.— М., 1978.— С. 188.) Кол Шәриф Сафагәрәйнең каләм сахибе — шагыйрь булганлыгын да искәртә.

6 Шәриф, мљселман галим-шагыйрьләренә хас булганча, фикерен Коръән сүрәләре, аятьләре белән ныгыта.

7 Легендар Мисыр фиргавене, явыз Нәмруд.

8 Имансыз Иван — Иван Васильевич Грозный (1530 — 1584), Казанга берничә яулап алу походлары оештырган, 1552 елда Казанны алган урыс патшасы.

9 Пулат бәк — Казан ханлыгында хан идарәсенең таянычы булган Булат бәк Ширин, ул бу әсәрдә сурәтләнгән 1550 елга кадәр үлгән була.

10 Булат Ширинның улы Нургали Ширин, аның салдырган мәчете —Сљембикә манарасы янындагы Мљрәле мәчете. Ул мәчет бинасының љске катында бүгенге кљндә ашханә урнашкан. Нургали Ширин Казан ханлыгының йогынтылы дәүләт эшлеклесе була.

11 Атаклы Иран шагыйре Фирдәүсинең «Шаһнамә» дастанының каһарманнары Дара (борынгы Иран шаһы Дарий) һәм Искәндәр (җиһангир Александр Македонлы).

12 Хан Морҗалый — тарихи чыганакларда бу топоним беренче тапкыр искә алына, борынгы Казандагы Хан сарае капкасы. Ул, Казанның тљп капкасы булып, Хан капкасы (Царево ворота) дип, урыс чыганакларына да кереп калган. (Кара: Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. — М., 1991. — С. 143.) Моҗралы — кабере дигән сүзне белдерә.

13 Акмљхәммәд углан, чыгышы белән Кырымнан, ул Казанга Сафагәрәй белән килгән булса кирәк. 1551 елның июнендә Казанда кырымлыларга каршы ризасызлык башлана. Кырымлылар, хәлнең мљшкеллеген күреп, љч йљз кеше (бәкләр, угланнар, морзалар, казаклар) кинәт җыелып, Казаннан Кырымга качарга уйлыйлар. Бу вакытта урыслар, Чулман (Кама) һәм Нократ (Вятка) елгалары буйлап килеп, Казан ханлыгын блокадага алган булалар. Чулман буенда урыс засадаларын күреп, кырымлылар Нократ елгасына киләләр. Сал ясап аны кичеп ятканда, урыслар, кисәк һљҗүм итеп, качкыннарны кыралар. Алардан бары 46 кеше генә исән кала. Исән калганнарны әсир итеп Мәскәүгә озаталар һәм анда җәзалап үтерәләр. Алар арасында Сафагәрәй хан алае азманы Кучак (Кощак) углан, Барбулсын углан, Турчы бәк, Баһадир мирза, Шаһиәхмәт мирза һ.б. була, һәлак булучылар арасында Акмљхәммәд угланның да булганлыгы аңлашыла. Чљнки 1551 елның июлендә Мәскәү белән солых тљзегәндә, килешүнең бер маддәсе буенча, Казаннан качкан кырымлыларның гаиләләрен Казан хљкүмәте тотып бирергә тиеш була. Килешүдә тотып биреләсе кешеләр арасында Кучак угланның ике улы һәм Акмљхљммәд угланның улы аерым атала. Шунлыктан Акмљхәммәд угланның 1551 елның 1 июнендә, Нократ (Вятка) елгасы буендагы бәрелештә әсир алынып, Мәскәүдә җәзалап үтерелгәнлеге аңлашыла.

14 Кол Мљхәммәд сәйед — Казанга Хаҗитархан шәһәреннән килгән Мансур сәйеднең улы. Мансур сәйед 1546 ел башында Казанда Сафагәрәйгә каршы Мәскәү яклы бәк-морзалар оештырган фетнә вакытында хан белән пайтәхеттән чыгып китә. Алар Әстерханга юл тоталар. Аның язмышы шул вакыттан соң ачык түгел, ләкин Кол Шәрифнең шушы язмасыннан аңлашылганча, 1550 елның башына кадәр ул үлгән була инде. Мансур сәйеднең улы — Кол Мљхәммәд сәйед, аның урыс елъязмаларындагы исеме Кол Шәриф сәйед (мулла). Шуннан чыгып Мансур улының тљп исеме Мљхәммәд Шәриф икәнлеге аңлашыла, ә кол атамасы әлеге сәйеднең суфилардан икәнлеген, ягъни Әхмәт Ясәви тәрикасын тотучы икәнлеген белдерә. «Зафәрнамә-и вилаяте Казан» авторы тыйнаклык җәһәтеннән үзенең Казан дәүләтендә тоткан урынын тулысынча ачмый, үзен Шәриф Хаҗитархани дип тыйнак кына күрсәтә.

15,16 Рљстәм, Баһрам — фарсы шагыйре Фирдәүсинең «Шаһнамә» дастанындагы батыр образлары.

17 Барбулсын аталык. Бу әсәрдә тасвирланган 1550 елда Казанның Аталык капкасын саклаган. Әлеге капка хәзерге Казан Кремленең кљньяк-кљнчыгышында урнашкан булган. Барбулсын углан чыгышы ягыннан Кырымлы, 1551 елның июнендә Казаннан качкан 300 кеше арасында Барбулсын углан исеме дә телгә алына. Урыслар аны әсирлеккә алалар һәм Мәскәүдә 46 качак белән бергә җәзалап үтерәләр.

18 Бибарс бәк — Казанда яшәүче Бадрак ыруы бәге — Бибарс Растов. Чыганакларда (урыс елъязмаларында) Бибарс һәм аның кардәшләре Себер бәкләре дип аталалар. Бу аларның Казан шәһәрендәге Тљмән капкасы сакчылары булуларыннан калган бер атамага охшый. Бибарс Растов һәм аның туганы Янбарс Сафагәрәйнең иң ышанычлы кешеләреннән булалар. Безнең уебызча, Сафагәрәй Казан башлыкларын Йосыф морзадан алып килеп Казанга утырткан. Янбарс Растов, 1549 елның март башында Сафагәрәйнең һәлак булуыннан соң, шул ук айда, хан сорарга Кырымга бара.

Мәскәү урыслары 1551 елны Казан дәүләтенең тау ягын басып алгач, Бибарс Зља каласына Казан илчеләре белән солых турында сљйләшүләр љчен бара.

1551 елның 16 августында тигезсез солых шартлары буенча Казанга хан булып Мәскәү колы Шаһгали утыра. Аның дошманлыгын белгән Казан бәкләре оппозиция оештыралар. Оппозициянең йљрәге булып Бибарс һәм Янбарс Растовлар була. Казандагы урыс вәкиле Д.Ф.Палецкий һәм Шаһгали хан бу эштән хәбәрдар булалар һәм мәкер юлы белән оппозициядә торган җитмешләп бәкне суеп чыгуны оештыралар. Алар арасында Бибарс һәм Янбарс Растовлар, Колай морза, Кадыш баһадир, Карамыш углан кебек кешеләр дә була. (Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства.— М., 1991.— С.139—140.)

19 Бу урында сүз Явыз Иван җитәкләгән урыс гаскәренең 1550 елның 12 февралендә Казанга яу белән килеп, аны алырга маташуы турында бара. Казан каласы Болак һәм Черек күл ягыннан урыслар тарафыннан чолганып алына.

Урыс елъязмаларының хәбәренә караганда, Иван Грозный, Казанны 14 кљн камап торганнан соң, җиңелеп, 25 февральдә Мәскәүгә кайтып китәргә мәҗбүр була. Елъязма авторлары аларның Казанны ташлап китүен яңгырлар, язгы ташулар башлану белән аңлаталар, ләкин февраль һәм мартта язгы ташулар, яңгырларның булуы шикләндерә. Алар бу килүдә Казан янында хәрби җиңелүгә юлыгып качканнар.

20 Әфләтун — борынгы юнан фикер иясе Платон, яңа эрага кадәр 427 — 347 елларда яшәгән.

21 Аристу — борынгы юнан хакиме Аристотель, безнең эрага кадәр 384 — 323 елларда яшәгән.

22 Бу мәгълүматлардан Шәриф Хаҗитарханиның тљпле белемле шәхес булганлыгы күренә. Ул йолдызлар, планеталардан хәбәрдар булган. Шуның белән бергә шагыйрь утлы туп снарядларының тљзелешеннән дә хәбәрдар, аларның хәрәкәт траекторияләренә дә күзәтүчән анализ ясый.

23 Милади календаре буенча 1550 елның февраленә туры килә.

Әсәрне текстологик хәзерләүче һәм искәрмәләр авторы<br>*Марсель Әхмәтҗанов*

## ЗАФӘРНАМӘ-И ВИЛАЯТЕ КАЗАН
## ПОБЕДА КАЗАНСКОЙ СТРАНЫ

***

Әлхәмдүлиллаһ раббил-галәмин, шљкер сәңа,
Үзең кабул бирдең иман безгә.
Ул бәдбәхет шәйтан-ләгыйнь гадәтендин
Кыйлды йарлык, бирде йаулак иман безгә.

«Раббанә, золемнә, әнфүсәна»,—
Халикым, разыйкым, барыйм сәңа.
Гыйльме хикмәт, тәүфыйк-тәгать, тљрлик сәна
Кыйлды тәшриф шәриф-ләтыйф Коръән безгә.

«Раббанә, фаг-фирләнә зљнубәна»,—
Телем аздым, йаздым, түздем, килдем бона.
Кәрәк — кәндү дәргяһыңдин сљргел вәйа,
Кәрәк — кәндү каршы алгыл ихсан безгә.

«Кљнтүм хәйра љммәтин ухриҗәт лин-нас»
айәтендин,
Љмидем күп ул Ходаның рәхмәтендин.
Безне кыйлды Мостафаның љммәтендин,
Йибәрде Мостафаны борһан безгә.

«Мән зә-әлләзи йәшфәгү»дин вилаятьсез,
Кем котылгай Рәсүледин гыйнаятьсез?
Аның күңле арар булса шәфәгатьсез,—

Калдык камугъ йите тәмугъ зиндан безгә.

«Лям тәкулүнә ма-ля тәфгалүн» айәтендә
Тәфсир кыйлмыш ул кыямәт атлыйгъ кљндә;
Үзе укыб, үзе тотмас данишмәндкә,
Ирекләндерер љч йљз алтмыш бәла безгә.

«Хљзүһљ фәгалүһљ» хитабындин,
Ки куркармын «Сљммәл-җәхим» гыйкабындин.
Укыб-белеп тотмадык без хитабындин,—
«Йа-вәйләти ләййәтәни» дәрман безгә.

Үзең белгел, йангыл имди, и Кол Шәриф,
Тәхсил тийү бар гомерең кыйлдың тәләф.
Йекетлектә тәүбә кыйлмак — гыйнаять ризык,
Йазыкларны йарлыкали гофран безгә.

*Тәрҗемәсе*:

Аллага, Галәмнең хуҗасына, дан булсын,
шљкер сиңа!
Үзең кабул бирдең иман безгә,
Ул бәдбәхет шайтан-ләгыйнь гадәтеннән
Ярлыкады, бердәнбер иминлек бирде безгә.
«Безнең нәфсебезне безгә залим кыйлма»,—
Яратучым, ризык бирүчем, барам Сиңа,
Хикмәт гыйлеме, тәүфыйк-тәгать*,
тљрле мактаулар,
Хљрмәтләр күрсәтеп, кадерле-гүзәл Коръән
бирде безгә,
«Раббыбыз, безнең гљнаһларыбызны гафу ит»,—
дип,
Телем белән күп сљйләдем, яздым, түздем,
килдем моңа,
Кирәк икән — үз ишегеңнән ку син (безне)
читкә,
Кирәк икән — Аллаһның Үзе, каршы алып,
безгә изгелеген кыйлсын иде,
«Кешеләр арасыннан хәерле бер љммәт**
чыгардым» аятеннән
Љметем бар булсын иде ул Ходаның
рәхмәтеннән,
Безне Мљхәммәт пәйгамбәр љммәтеннән
яратты ул,
Мљхәммәт пәйгамбәрне дәлил итеп безгә
җибәрде ул.
«Ул кемсә*** безгә шәфәгатьче (мәгънәви хуҗа)
булды» аятеннән
Кем котыла алсын ярдәмчесез,
Мљхәммәт пәйгамбәр ярдәменнән башка?
Аның**** күңеле эзләр булса арадашчысыз
изгеләрне,—
Без бљтенебез җиде тәмуг-зиндан эчендә
калырбыз бит,
«Үзе эшләмәгән гамәлләрдән ничек халыкка
нәсыйхәт бирер» аятендә
Аңлатып бирде Ул: «кыямәт» дип аталган

кљндә,
Үзе әйтеп тә, шул гамәлләрне үзе тотмаган
галимгә,
Әйтеп торыр љч йљз алтмыш бәла безгә.

«Аллаһ теләгәнен эшләр: Ул алыр,
Ул эшләр» дигән сүздән,
Ахыргы урын җәһәннәм булуыннан—
газап чигүдән куркам,
Без укыдык-белдек, әмма тотмадык
Аллаһ нәсыйхәтеннән,—
«Ни үкенеч! Әй, булса иде!» сүзләре генә
юаныч безгә.
Үзең бел дә ян инде, и Кол Шәриф,
«Белем алам» дип, бљтен гомереңне уткәреп
бетердең.
Егет чакта тәүбә итү Аллаһның
ярдәме (ризыгы) кебек ул,
Гљнаһларны ярлыка инде, Аллаһ, безнең.

***

Башың күтәр гафләтдин, гафил торма,
һу тигел.
Күзең ачкыл уйкудин, гафил торма,
һу тигел.
Һу-һу тийү һу кошы, акар күзендин йәше,
Кљйеп эче һәм тышы, гафил торма,
һу тигел.
Гашыйклары очарлар, гарше шахига
кунарлар,
Һу, дип дидар куларлар, гафил торма,
һу тигел.
Йите әкълим гизәрләр, андин күккә агарлар,
Бер кадәмдә йитәрләр, гафил торма,
һу тигел.
Һу бәхригә чумарлар, гаувас булып батарлар,
Һу дљрләрин тирәрләр, гафил йљрмә,
һу тигел.
Дәргяһ капуг ачыкдыр, рәхмәтләри анукдыр,
Күзең ачып бакып тор, гафил йљрмә,
һу тигел.
И Кол Шәриф, тынмагыл, тљнләр йатып
оймагыл,
Хак зекрени куймагыл, гафил йљрмә,
һу тигел.

*Тәрҗемәсе:*

Башың күтәр ваемсызлыктан, белми торма,
«Аллаһу» диген.
Күзең ач син йокыдан, белми торма,
«Аллаһу» диген.

Һу-һу, дияр һу кошы*, агар күзеннән яше,
Кљеп эче һәм тышы, белми торма,
«Аллаһу» диген.
Гашыйк булганнар очарлар, гарше шахига**
кунарлар,
«Аллаһу» дип очрашу кљтәрләр, белми торма,
«Аллаһу» диген.
Аллаһу диңгезенә чумарлар, су асты
йљзүчесе булып батарлар,
«Аллаһу» энҗеләрен чүпләрләр, белми торма,
«Аллаһу» диген.
Оҗмах ишеге ачыктыр, рәхмәтләре
билгеледер,
Күзең ачып карап тор, белми йљрмә,
«Аллаһу» диген.
И Кол Шәриф, тынма син, тљннәрен ятып
йоклама,
Аллаһка зикер әйтүне ташлама, белми йљрмә,
«Аллаһу» диген.

***

И күңел, бил баглама, күпне кичүргән
дљньядыр,
Бу үлүм ширбәтин халыкга ичүргән
дљньядыр.
Сән сагынма дљньяда мән бакый калгаймән
тийү.
Күп йанар вакытта чирагларны очурган
дљньядыр,
Угылны атадин айуруб, кызны анадин тәкый,
Йыглатыб бер-бер ишекдә, зари кыйлган
дљньядыр.
Әүвәлени кемсә билмәс, ахырыни һәм тәкый,
Әүвәле һич, ахыры һич, бер кљһнәи дљньядыр.
Кол Шәриф, атаң-анаң сәндин борынгылар
кани,
Барчани куйныга (алып), ашна кыйлган
дљньядыр.

*Тәрҗемәсе:*

И күңел, билеңне бума (дљнья дип),
күпне кичергән дљнья бу,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дљнья бу.
Син уйлама, дљньяда мин мәңгегә калырмын
дип,—
Күп янар вакытта утлар очырган дљнья бу.
Угылны атадан аерып, кызын да анадан
шулай ук,
Елатып бер-бер ишектә, зар иттергән
дљнья бу.
Әүвәлен беркем белмәс, ахырын да шулай ук,

Әүвәле юк, ахыры юк, бер сәләмә дљнья бу.
Кол Шәриф, атаң-анаң синнән никадәр
борынгылар иде,—
Барчаны куенына (алып), әшнә иткән
дљнья бу.

***

Мљнаҗәтдә моңлугъ кәрәк, иҗабәти булса
андин,
Күзи йашлигъ, бәгъри башлигъ булмагунча
булур кандин.
Ир сәхәрдә кубубән, тулдырмайен күздә
йаши,
Љмид тутмак мљхаль ирер, капугъ баглигъ
камугъ йандин.
Сәхәр купсаң, нийаз кыйлсаң, соң нийазың
кулга алсаң,
Иҗабәтдер дога кыйлсаң, иҗабәти булса
андин.
Үзиндә булур иран йыкган, күрәр нуры
Аллаһыны,
Фида булур максуд-морад, рахте гыйшрәт
кызыл җандин.
Нәфәси җиһад кыйлса, күзләрендин кан-йаш
акса,
Раббе тийү аңа бакса, кәлүр ләббәйкә
йљз-мең йандин.
Морад кәрәк ирсә сәңа, хакыйкыйә
йангыл аңа,
Гамәл кыйлып тљндин-тљңә, чыкмагунчә
бәһ бундин.
Рийазәтнең бутасында сыз гаурәтин,
и Кол Шәриф,
Кәнҗе гыйшкы кәрәк ирсә, алтун-кљмүш чыка
кандин.

*Тәрҗемәсе:*

Мљнәҗәттә моңлылык кирәк, кабул итүе
(Алланың) шуннан торса әгәр,
Күзең яшьле, бәгърең башлы булмаса,
каян табылыр ул (моңлылык)?
Ир сәхәрдә тору белән тутырмаса күзен яше
белән,
Љметләнү (Алла ризалыгына) мљмкин
булмас,
оҗмах ишеге бикле булыр бар яктан да.
Сәхәргә торсаң, нияз* кыйлсаң, соңыннан
ниязыңны үзеңә кулланма итеп алсаң,
Кабул итәр (Алла), дога кыйлсаң,
Алланың ярлыкавы шуңанда булса.
Үзендә ирлек һиммәте** булган кеше Алланың
нурын күрер,

Дљньяви максат-морадларын корбан итәр ул
(шул юлда), рәхәт тормышы китәр җаннан.
Әгәр нәфсесе белән сугышса, күзләреннән
кан-яшь акса,
Раббем, диеп, аңа бакса, килер ләббәйкә***
йљз-мең яктан.
Морад кирәк булса сиңа, хакыйкатьтә
ян син аңа,
Гамәл кыйлып тљннән тљнгәчә, яхшылыктан
(үзеңне камилләштерүдән) читкә чыкмыйча.
Риязәт**** билбавындагы оят җирне***** сызып
ташла, и Кол Шәриф,
Алла гыйшкы хәзинәсе кирәк булса,
алтын-кљмеш каян чыгар башкача?

***

Хакыйкать чын гашыйклар
Кергел юлга мәрданә.
Раһнамәдер бу юлда
Шәйхе Гаттар диванә.

Галимнәргә раһнамә,
Дәрвишләрне моктәда,
Һәрбер сүзе дљрр-данә
Шәйхе Боһлул диванә.

Гыйшк кљфрен имам иткән,
Галәме бәрдар иткән,
Җаныны корбан иткән
Шәйхе Мансур диванә.

Гыйшк багының бер гљле,
Менгәне рух Дљлдљле,
Хакның кавшкан былбылы
Шаһ Борыкай диванә.

Күңле бозык-вәйранә,
Дљньялыкдин бигянә,
Шәүкь утыга пәрванә,
Хисаметдин диванә.

Гаибне хазир кыйлган,
Мљшкилне асан кыйлган,
Йите үлеккә җан биргән
Баһаветдин диванә.

Гасалары кулында,
Һиммәт коры билендә,
Аллаһ йады күңелендә
Шәмс Тәбризи диванә.

Мәгърифәткә мәстанә,
Игәсигә дустанә,
Кабре — олуг астанә,

Вәйс-Карани диванә.

Мәгърифәткә кол булган,
Гыйшкта янып кьл булган,
Талибләргә йул булган
Кол Шәрифә диванә.

*Тәрҗемәсе:*

Хакыйкать чын гашыйклар
Юлына кер ирләрчә;
Юл күрсәтүчедер бу юлда
Шәйхе Гаттар[1] диванә[2].

Галимнәргә юл күрсәтүче,
Дәрвишләрне ияртүче,
Һәрбер сүзе энҗе-мәрҗән
Шәйхе Боһлул[3] диванә.

Аллага гыйшыкның
кьферлеген имам иткән,
Галәм биеклегенә күтәрелгән,
Шуңа җанын корбан иткән
Шәйхе Мансур[4] диванә.

Гыйшык бакчасының бер гьле,
Менгәне — рух Дьлдьле[5],
Хакның кавышкан былбылы
Шаһ Борыкай[6] диванә.

Күңеле бозык-җимерек,
Дьньялыкка чит-ят булган,
Кьчле теләк утына күбәләк булган
Хисаметдин[7] диванә.

Күренмәгәннәрне белдергән,
Авырлыкны җиңел кыйлган,
Җиде үлеккә җан биргән
Баһаветдин[8] диванә.

Таяклары кулында,
Тырышлык билбавы билендә,
Аллаһны телгә алу күңелендә
Шәмсе Тәбризи[9] диванә.

Мәгърифәткә[10] исергән,
Рухи җитәкчесенә дус булган,
Кабере олуг хаҗ кылу урыны булган
Вәйсел-Карани[11] диванә.

Мәгърифәткә[12] кол булган,
Аллаһка гыйшкында янып кьл булган,
Шәкертләренә юл булган
Кол Шәрифи диванә.

ИСКӘРМӘЛӘР

Кол Шәриф әсәрләре бу җыентыкка төрле кулъязма һәм басма чыганаклардан җыеп китерелә. Әлбәттә, шагыйрьнең үз кулы белән язган кулъязмалар, аның автографы безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән. Ә безгә билгеле булганнарының, тарихның шулкадәр рәхимсез һәм кырыс янгын-давылларына да бирешмичә, өзек-өзек кенә булса да бүгенге көнгә кадәр сакланып-килеп җитүләре үзе бер могҗиза булып карала ала.

Бу әсәрләрнең Кол Шәрифнеке икәнлеген без каян беләбез соң?

Урта гасырлардагы бөтен Шәрык әдәбиятларында, шул исәптән татар әдәбиятында да, бик матур бер традиция яшәп килгән: һәр шагыйрь шигъри әсәрләренең ахырына, үз әсәрен башка авторларның әсәрләре белән буташтырмасыннар өчен, үзенең исемен дә теркәп куя торган булган. Бу барыннан да элек газәл, касыйдә, мәснәви, кыйсса һ.б. жанрларда мәҗбүри кагыйдә булып исәпләнгән.

Шушы традициягә нигезләнеп, Кол Шәриф тә һәр әсәренең азагында үзенең исемен китерә. Без бу җыентыкка шигъри әсәрләрне нәкъ менә шушы кагыйдәдән чыгып тупладык һәм бары шушы, урта гасырларда бер генә шагыйрь тарафыннан да бозылмый торган канунга таянып кына без бу китапта китерелә торган әсәрләрнең авторы Казан ханлыгы чоры татар шагыйре Кол Шәриф дип әйтергә җөрьәт итәбез.

**«Башың күтәр гафләтдин…»** Әсәр тексты 1883 елда Казан университеты нәшриятында чыккан «Бакырган китабы» исемле шигырьләр антологиясендә XII гасыр төрки шагыйре Сөләйман Бакыргани шигырьләре белән бергә басылган (28 нче бит). Текст шуннан алынды. Әсәрнең кулъязма нөсхәләре билгеле түгел.

**«И күңел, бил баглама…»** Әсәр тексты 1883 елда Казан университеты нәшриятында чыккан «Бакырган китабы» җыентыгында Сөләйман Бакыргани шигырьләре белән бергә басылган (29 нчы бит). Текст шуннан алынды. Кулъязма нөсхәсе билгеле түгел.

Бу шигырь юлы китапта «Барчаны куйныга ашна кыйлган дөньядыр» дип бирелгән. Шигырьнең эчке яңгырашы буенча монда «алып» сүзе төшеп калганлыгы сизелеп тора; шигырь юлының иҗек саны да шуны таләп итә.

**«Мөнаҗәтдә моңлугъ кәрәк…»** Шигырь тексты 1883 елда Казан университеты нәшриятында чыккан «Бакырган китабы» җыентыгында Сөләйман Бакыргани шигырьләре белән бергә басылган (28 нче бит). Текст шуннан алынды. Кулъязма нөсхәсе билгеле түгел.

**«Әлхәмдүлиллаһ раббил-галәмин, шөкер сәңа».** Шигырь тексты 1883 елда Казан университеты нәшриятында чыккан «Бакырган китабы» җыентыгында Сөләйман Бакыргани шигырьләре белән бергә басылган (28 — 29 нчы битләр). Текст шуннан алынды. Кулъязма нөсхәсе билгеле түгел.

Мөрәббәгъ формасында язылган бу шигырь нигезендә мөселманнарның изге китабы Коръәннең аятьләреннән чыга торган фикерләр-мәгънәләр салынган. Автор шул аятьләргә карата үзенең мөнәсәбәтен, үзенең карашын белдереп бара.

**«Хакыйкать чын гашыйклар…»** Шигырь тексты 1847 елда Казанда чыккан «Бакырган китабы» җыентыгында XII — XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре белән бергә басылган. Текст шуннан алынды. Кулъязма нөсхәсе билгеле түгел.

Мөрәббәгъ формасында язылган бу шигырьдә автор ислам тарихында аеруча күренекле булган суфиларны санап чыга, аларның дин өлкәсендәге эш-гамәлләрен бәян итә.

1 Шәйхе Гаттар — атаклы фарсы шагыйре Фәридетдин Гаттар (1119 — 1221). Суфи, йөздән артык поэма авторы. Шулардан «Мантыйкыт-тайур», «Пәнднамә» поэмалары татарчага да тәрҗемә ителгән һәм халкыбыз арасында аеруча популяр булган. 110 яшендә, 1221 елда монголлар Нишапурны алгач, шагыйрьне кулга төшерәләр һәм Чыңгыз ханны мактап әсәр язарга кушалар. Ул баш тарта һәм җәзалап үтерелә.

2 Диванә — суфиларда әйтелә торган бәя бирүче термин. Аллаһы Тәгаләнең серләренә төшенгән, диндарлыкта камиллеккә ирешкән, экстазда яшәүче суфиларга карата әйтелә.

3 Шәйхе Бөһлул — урта гасырларда үзенең аскетлыгы белән дан тоткан Бөһлул дәрвиш күздә тотыла. Яшәгән еллары билгеле түгел.

4 Шәйхе Мансур — атаклы суфи шагыйрь Хөсәен ибне Мансур Хәллаҗ. Үзен Аллаһы Тәгалә дип белдерүдә гаепләнә һәм 922 елда һәлак ителә.

5 Дөлдөл — Мөхәммәд пәйгамбәр атының исеме.

6 Шаһ Борыкай — XIII гасырда яшәгән суфилардан берсе, Шәмсетдин Тәбризинең укучысы.

7 Хисаметдин — Җәлалетдин Руминың дәрвише, аның мәснәвиләрен язып барган Хисаметдин Чәләби — Хәсән бине Мөхәммәд (Ахи Төрек углы).

8 Баһаветдин — Баһаветдин Вәлид, Мөхәммәд ибне Әхмәд Хатиби, суфиларның шәехе, динче галим, Җәлалетдин Руминың әтисе (1148 — 1231).

9 Шәмсе Тәбризи — XII гасыр ахыры — XIII гасырның беренче яртысында яшәгән суфи шагыйрь, мистик Шәмсетдин Мөхәммәд Тәбризи. Җәлалетдин Руминың якын дусты һәм остазы.

10 Мәгърифәт — бу термин биредә гадәти аң-белемне генә аңлатмый. Суфичылык тәгълиматы буенча, суфилык юлына баскан мөселман үзенең күңеле-рухы белән Аллаһка якынаю юлында түбәндәге дүрт рухи баскычны үтәргә тиеш: шәригать, тарикать, мәгърифәт һәм хакыйкать. Мәгърифәт баскычында суфи Аллаһка якынаю юлында кирәк тиешле гыйлем-белем ала, үз-үзен рухи яктан тәмам агартуга, ягъни мәгърифәткә ирешә; үзе мөршид (рухи җитәкче) булып, суфи шәкертләр тәрбияли ала.

11 Вәйсел-Карани — мөселман дөньясында дан-шөһрәт алган шәхес, әүлия, Мөхәммәд пәйгамбәр заманында яшәгән иң беренче суфиларның берсе.

12 Мәгърифәт — бу термин монда да алда күрсәтелгән мәгънәдә кулланылган.

Әсәрләрне текстологик хәзерләүче һәм искәрмәләр авторы
*Әнвәр Шәрипов*

# II бүлек

# КОЛ ШӘРИФ:

# ТОРМЫШЫ, ЭШЧӘНЛЕГЕ ҺӘМ ШУЛ ЧОР ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ
## II раздел

# КУЛ ШАРИФ:
# ЖИЗНЬ И ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ

# И ТАТАРСКАЯ КУЛЬТУРА ЕГО ЭПОХИ

***Марсель Әхмәтҗанов,***

филология фәннәре докторы

## Сәйед Шакуловлар шәҗәрәсе

Соңгы вакытта җәмәгатьчелек арасында татар-мљселманнарның дини идарәсе җитәкчеләре арасында сәйед тә булырга тиеш дигән фикер таралып килә. Ул Татарстан җљмһүрияте мљселманнарының чираттан тыш корылтае узган кљннәрдә күтәрелде. Корылтайда мљфти хәзрәтләренең иң абруйлы ярдәмчеләреннән берсенә сәйед дәрәҗәсе бирергә кирәк дигән тәкъдим кертелде Бу хакта татар матбугатында берничә мәкалә дә басылып чыкты инде[1].

Сәйедләрнең кемлеге һәм аларның татар тарихында нинди урын биләүләре хакында бүгенге укучыларыбызның иң зур күпчелеге хәбәрдар түгел. Шунлыктан корылтайда күтәрелгән мәсьәләне — ягъни сәйедлекнең дини идарәгә кайтаруның традициясен аңлату љчен тарихи чыганаклар белән танышу кирәктер.

XIV — XVI гасырларда Алтын Урдада, Казан, Кырым, Хаҗитархан, Нугай Урдасы, Хан Кирмән ханлыклары тарихларында сәйедләр искә алына башлыйлар. Тарихи чыганаклар сәйедләрне татар ханлыкларында мљселманнарның иң љлкән дини җитәкчеләре итеп күрсәтәләр.

1524 еллар чамасында Казанда булып киткән немец сәяхәтчесе Сигизмунд Герберштейн үзенең юлъязмаларында сәйедне татарларның «баш имамы» дип атый[2]. Сәйед белән хан да хисаплаша торган булган. Казан тарихында түбәндәге сәйедләр мәгълүм:

Бураш сәйед 1491 — 1507 елларда искә алына[3].

1512 — 1516 елларда Шаһхљсәен сәйед Казан белән Мәскәү арасындагы илчелек мљнәсәбәтләрендә катнашып йљри[4].

Шаһхљсәен сәйед Шакуловлар шәҗәрәсендәге 28, 29, 30 буыннарда антропонимнары Шаһ компонентына ия булган — XVI гасырның беренче яртысында яшәгән сәйедләрнең кардәше булырга ихтимал. Шәҗәрәдә бу исем күрсәтелмәгән, чљнки ул гына түгел, анда Казанга каршы сугышкан Касыйм татарлары гаскәрендә булган Ак сәйед исеме дә юк.

1546 елда Казанда Беюрган сәйед булып тора. Сафагәрәй тәхеттән тљшерелгәч, ул Казанда вакытлы хљкүмәтне җитәкли. Беюрган сәйед 1551 елның октябрендә Шаһгали хан кушуы буенча җәзалап үтерелә.

1546 елда Сафагәрәй Мансур сәйед (Әстерханнан Казанга килгән була) белән берлектә Казаннан Әстерханга китә[5]. Димәк, Мансур сәйед Казанда күпмедер вакытлар дин башлыгы булып торган[6]. Ул озакламый вафат булган, күрәсең, чљнки бу елдан соң аның исеме чыганакларда күренми.

Казан тарихында исеме сакланып калган янә бер сәйед — Кол Шәриф (Шәриф Хаҗитархани). Аның исеме 1550 елдан күренә башлап 1552 елның 2 октябренә кадәр тарихта язылып килә. Ул шул кљнне соңгы тамчы канына кадәр Ватанын саклап һәлак була[7].

Казан ханлык башкаласы булып торганда, анда Корайыш дип аталган бистә булуы да кызыклы. Ихтимал, ул бистә Казан сәйедләре белән бәйле булса кирәк.

Казан ханлыгы сәйедләренең абруйлы булуларын Сәхибгрәй хан тарафыннан 1523 елда бирелгән тарханлык ярлыгы да раслап тора. Ул ярлыкта алар «садати гозам» дип йљртеләләр[8].

Сәйедләрнең Кырым ханлыгында да олы дин башлыгы булулары 1531 елда Сәгадәтгәрәй хан биргән ярлык текстыннан да беленә[9].

Тарихта сакланган иң тулы мәгълүмат Касыйм ханлыгы сәйедләре турында. Бу мәгълүматлар чыганагы булып сәйед Шакуловларның нәсел шәҗәрәсе хезмәт итә. Әлеге нәсел шәҗәрәсен 1970 елда сәнгать фәннәре докторы Фоат Хљсәенович Вәлиев Касыйм шәһәреннән табып алып кайтты һәм бу юлларның авто-

рына бүләк итте. Шакуловлар шәҗәрәсе љч озын кәгазьдә язылган, аларның текстлары, бер-берсеннән тулырак булып, XVIII—XIX гасырларда гарәп әлифендә эшләнгән күчермәләрдән гыйбарәт… Аларга кыскача тасвирлама биреп узабыз:

Беренче текст 112 см озынлыктагы, 21 см киңлектәге зәңгәрсу тљстәге кәгазьгә алсу һәм кара каралар белән XVIII гасыр ахырында язылган. Ахыргы љлеше ертылып югалган. Арткы ягында Ф.Х.Вәлиевнең автографы бар. Ул Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Мирасханәсендә 99 коллекциядә, 1 тасвир, 209 санлы эш булып саклана.

Икенче текст 197 см озынлыкта, 18 см киңлектә XIX гасырның беренче чирегендә эшләнгән яхшы кәгазьгә кара белән гарәп әлифендә язылган. Ул шәҗәрәләр коллекциясендә 264-б эш берәмлеге белән саклана. Бу әлегә иң соңгы текст булып тора.

Љченче текст 143,5 см озынлыктагы, 17,5 см киңлектәге XVIII гасыр кәгазенә кара белән гарәп әлифендә язылган. Мирасханәдә 264-а эш берәмлеге белән саклана.

Беренче, љченче текстларда беркадәр гарәп телендә язылган искәрмәләр дә бирелгән.

Моннан тыш Шакуловлар шәҗәрәсенең күчермәләре урыс тарихчысы В.В.Вельяминов-Зернов (1830 — 1904) һәм татар галиме Ризаэддин бине Фәхретдин (1859 — 1936) кулларында да булганлыгы мәгълүм. Алар кулындагы кулъязма текстлар, XIX гасырда күчерелеп, татар телендә язылган байтак тарихи искәрмәләргә дә ия булып торганнар. В.В.Вельяминов-Зернов үз кулындагы шәҗәрә текстын љлешчә генә «Исследование о касимовских царях и царевичах» исемле 1863 — 1887 елларда чыккан дүрт томлык хезмәтендә файдаланган.

Ризаэддин бине Фәхретдингә Касыймнан җибәрелгән «Шакуловлар шәҗәрәсе» «Шура» журналының 1914 елгы 22 нче саны тышлыгында басылып чыккан. Ул 36 буыннан тора. Шәҗәрә кулъязма текстлардан кыскарак.

Кулъязма текстларның Мирасханәдә 264-б эш берәмлеге булып сакланганы буыннар ягыннан иң тулысы булып тора. Түбәндә аның текстын тулысынча китерәбез. 209 эш берәмлеге белән саклանучы 1 кулъязма буыннарны күрсәтү ягыннан кыскарак, ләкин искәрмәләргә баерак. 264-а эш берәмлеге белән саклანучы текстта гарәп телендә искәрмәләр бар һәм анда 35 буыннан башлап 264-б шифрлы текстта булмаган буыннар чылбыры китерелә.

«Шура» журналында басылган текст 264-б текстына љстәрлек яңалыкка ия түгел. Ләкин аны журналга җибәрүче кеше Касыйм шәһәрендә 1914 елда Шакулов фамилиясен йљртүчеләрнең күп булуларын яза, тик аларның буыннары, исемнәре шәҗәрәдә күрсәтелмәвенә үкенеч белдерә.

Мәкаләнең күләме чикләнгән булу сәбәпле, 264-б кулъязмасыннан башкаларының мәгълүматларын кабатланмаган урыннарын сайлап кына укучыларга тәкъдим итәбез.

## ШАКУЛОВЛАР ШӘҖӘРӘСЕ ТЕКСТЫ
(264-б кулъязма)

**1 буын**
Габделмәннан

**2 буын**
Һашим

**3 буын**
Габделмоталлиб

**4 буын**
Әбүталиб
Габдулла
Хәзрәти Габбас разый Аллаһе ганһе
Хәзрәти Хәмзә разый Аллаһе ганһе

**5 буын**
Хәзрәти Гали кәрим (юмарт)
Сәрвәри әнбийә Мљхәммәд Мостафа сәлаллаһу га-

ләйһи вәсәллам
Габдулла разый Аллаһе ганһе

**6 буын**
Хәсән разый Аллаһе ганһе
Сәйед Хљсәйен разый Аллаһе ганһе
Бинтәи сәйедәи Фатыйма әл-Зљһрәи (сәйед Хљсәйен-нең хатыны)

**7 буын**
Сәйед Зәйнелгабидин имам

**8 буын**
Сәйед Мљхәммәдбакый имам

**9 буын**
Сәйед Җәгъфәр әс-Сыйддыйк имам

**10 буын**
Сәйед Идрис
Сәйед Муса кязыйм (түзеп торучы) имам
Гали ансар (Мәдинәдә яшәүче Мљхәммәд тарафда-ры) сәйед

**11 буын**
Сәйед Мљхәммәдшафигъ
Сәйед Муса әр-разый имам
Сәйед Җарулла

**12 буын**
Сәйед Мљхәммәдтәкый имам

**13 буын**
Сәйед Галянәкый

**14 буын**
Сәйед Хәсән әл-Гаскәри

**15 буын**
Сәйед Мљхәммәд Наһдемир

**16 буын**
Сәйед Мир Йуныс
Сәйед Мљхәммәд Сљмгани

**17 буын**
Сәйед Мирбакый
Сәйед Йосыф Һәмадани

**18 буын**
Сәйед Исмәгыйль

**19 буын**
Сәйед Моддәвеши

**20 буын**
Сәйед Әхмәд Хисараи ата

**21 буын**
Сәйед Әхмәд Ракенеддин Солтан

**22 буын**
Сәйед Гали хакани

**23 буын**
Сәйед Мостафа
Сәйед Мљхәммәд Бохари
Сәйед Мәхмүд

**24 буын**
Сәйед Йегет Әхмәд

**25 буын**
Сәйед Шаһи Әхмәд

**26 буын**
Сәйед Хилват

**27 буын**
Сәйед Мљхәммәд

**28 буын**
Шаһнур сәйед
Сәйед Шаһбай
Шаһхан сәйед
Шаһҗан сәйед

**29 буын**
Сәйед Шаһмљхәммәд

**30 буын**
Сәйед Шаһколый (Шакуловлар фамилиясе моннан киткән.— *М.Ә.*)

**31 буын**
Сәйед Борһан сәйед

**32 буын**
Сәйед Кашки

**33 буын**
Сәйед Бүләк сәйед

**34 буын**
Акмљхәммәд сәйед
Ишмљхәммәд сәйед

**35 буын**
Тинмљхәммәд сәйед

**36 буын**
Әхмәд сәйед

**37 буын**
Йагъкуб сәйед

**38 буын**
Биктимер сәйед

**39 буын**
Әхмәд сәйед
Мостафа сәйед
Муса сәйед
Сәйед Борһан сәйед
Акмљхәммәд сәйед
Габдулла сәйед

**40 буын**
Мортаза
Солтан Мљхәммәд сәйед
Салих сәйед
Ибраһим сәйед
Йосыф сәйед
Сљләйман сәйед

**41 буын**
Сәйфулла сәйед
Хәмзә сәйед

**42 буын**
Батыргәрәй сәйед
Хљсәйен сәйед

**43 буын**
Мљхәммәдҗан сәйед
Исмәгыйль сәйед
Хәсән сәйед
Котлымәт сәйед
Касыймхан сәйед
Борһан сәйед
Ибраһим сәйед

**44 буын**
Исмәгыйль сәйед
Мљхәммәд сәйед
Батыргәрәй сәйед
Фәрид сәйед
Мостафа сәйед
Исмәгыйль сәйед
Сәйед Әхмәд сәйед
Мостафа сәйед

**Мәрхәмәт итүче, рәхимле Аллаһ Хакына!**[10]
**Бу шәҗәрә Корайыш кабиләсе**
**Һашим ыруынықыдыр**

**209-а шифрлы кулъязма текстыннан љзекләр**

Текст 264-а кулъязмасының 36 буыны белән тәңгәл килә. 264-б кулъязмасының 35 буынынннан аерыла башлый һәм 36 буын Корбанай сәйед исеме белән туктый. Ихтимал, бу нљсхә тагын да дәвам иткән булгандыр, чљнки ахыргы љлеше ерткаланып љзелгән.

209 шифрлы кулъязмада аерым исемнәр янында гарәп телендә язылган берничә искәрмә бар. Шулай ук буыннар килешендә аермалар күренә.

**1 буын**

Габделмоталлаб

**2 буын**
Әбүталиб
Габдулла
Габбас

**3 буын**
Галикәрам
Мљхәммәд сәлаллаһу галәйһи вәссәлам
Габдулла

Тексттагы искәрмәдән: Габдулланың Мљхәммәд пәйгамбәрдән соң хәлифәи Рәшит дәүләте җирләрендә яшәгәнлеге аңлашыла. Хәлифә Һарун әр-Рәшид 785 ел румидә идарә итә башлый. Димәк, шәҗәрәне тљзүчеләр тарихи дәверләрне бутаганнар.

209 шифрлы текстта 11 буын, 20 исем сәйед Мљхәммәдшафигъ нәселенең Шам, Халеб, Багдад һәм башка гарәп җирләрендә таралуы күрсәтелә.

Шунда ук 11 буын, 22 исем янында сәйед Җарулла нәселенең кљнбатышта яшәве искәртелә.

20 буын сәйед Әхмәд Хисараи ата исеме турысында Бохараи шәрифтә булуы; Хәким ата Сљләйман белән бәйләнеше, Җәйхун (Амудәрья) буйларында яшәве язылa.

23 буын (37 исем) сәйед Мљхәммәд Бохари исеме турысында аның нәселенең Бохараи шәрифтә, Һиндстанда, Синдстанда (Пакыстан) таралуы язылa.

23 буын (38 исем) сәйед Мәхмүд нәселенең Тљркестанда, Коканд, Карши һ.б. урыннарда таралуы күренә.

28 буын (45 исем) Шаһхан нәселенең Кырым вилаятендә, Кубаньда, Дагстанда таралуы хәбәре бар.

28 буын (44 исем) Шаһбай сәйед нәселенең Болгар вилаяте, Хан Кирмән, Хаҗитархан һәм Идел буйларында таралуы язылган.

Соңгы әлеге искәрмә Шакуловлар нәселе шәҗәрәсенең яңарак заманнарда яңадан редакцияләнүен күрсәтә, чљнки анда Алтын Урда дәвере бљтенләй чагылмый кала. Шул ук вакытта андагы тљп татар дәүләтләрендә бер үк нәсел вәкилләренең таралышы раслана.

Шакуловлар шәҗәрәсенең тарихи хронологиясен аныклау љчен В.В.Вельяминов-Зернов файдаланган нљсхәдәге искәрмәләрне монда искә алып китү мљһим.

В.В.Вельяминов-Зернов язуына караганда, Казанны 1552 елда урыслар алган вакытта, алар ягыннан Ак сәйед Шәриф сәйед улы катнашканлыгы мәгълүм була[11].

Касыйм шәһәрендә 1587 елда Кашки сәйеднең зур дәрәҗәле кеше булуы В.В.Вельяминов-Зернов тарафыннан табылган Федор Иванович патша биргән ярлыкта искә алына[12].

Шулай итеп, Шакуловлар шәҗәрәсендәге 32 буын (50 исем) сәйед Кашкиның XVI гасырның икенче яртысында яшәгәнлеге ачыла. Касыйм ханнары заманында сәйедләр полклар белән җитәкчелек иткәннәр, һәм аларның аерым сарайлары булган[13].

Кашки сәйед улы — Бүләк сәйед. Аның кабере Касыймның Иске бистә зиратында сакланган. Шәҗәрәдә аның турында «Күзе ачык вә дәлилиге (мантыйгы.— *М.Ә.*) бар икән. Каберләре Иске бистә мазарындадыр» диелгән. «Сәйед Бүләк сәйед Иске Йортның йадкаре»[14].

36 буын (55 исем) Әхмәд сәйед XVII гасырның икенче яртысында яшәгән. Касыймның соңгы идарәчесе булган Фатыйма солтанның агасы Тинмљхәммәд сәйеднең (Тинеш сәйед Шакуловның) улы. Аның исеме Галикәй аталык васыятьнамәсендә дә искә алына. Урыс хљкүмәтенә тәрҗемәче булып хезмәт иткән. Ул 1680 елда урыс илчеләре Тяпкин һәм Зотов белән берлектә Кырымга җибәрелә һәм шунда 1681 ел башында үлеп кала[15].

37 буын (56 исем) Әхмәт сәйед улы Йагъкуб сәйед XVII йљзнең икенче яртысында яшәгән. Аның хакында В.В.Вельяминов-Зернов кулындагы шәҗәрә нљсхәсендә: «Йагъкуб сәйед Йалатма кальгасида үлгән. Түрә булып торган. Бер заманнарда Иске бистәдә (Касыймда.— *М.Ә.*) Арслан хан (1626 — 1627 елда үлә) берлән Фатыйма солтанның мазаратында такыя астына кереп, Иске бистәнеке бер хатын солтаннарның кәфеннәрен, гайре әсбапларын угырлап, суеп чыккан. Ягъкуб сәйед ул хатынны шул бистә таганында астырган»[16].

Фатыйма солтан үзе Бүләк сәйед улы Акмљхәммәд сәйеднең кызы була. Аның хакында безгә килеп җитмәгән шәҗәрәдә «Арслан ханны Тубыл-Тура дигән вилаятьтән алдырганнар. Акмљхәммәд сәйед кызы

Фатыйма солтанны алган хәләллеккә. Арслан хан үлгәннән соң, Хан Кирмәндә (Касыйм.— *М.Ә.*) чарича (царица.— *М.Ә.*) булып торган. Фатыйма солтандин соң хан киселгән»[17].

Югарыда китерелгән Шакуловлар шәҗәрәсе күчермәләре шактый кызыклы һәм кыйммәтле тарихи мәгълүматларга ия булып торалар. Аларда сәйедләрнең урта гасырлардан бирле татар иҗтимагый-дини тормышында үзәк фигуралар булып катнашып килүләре күренә.

Касыйм сәйедләренең нәселләре XX гасырга хәтле килеп җиткән. Шушы гасырның унынчы елларында Парижда Сорбонна университетын бетереп кайткан математик Сара ханым Шакулова (1887 — 1964) бу нәселдән соңгы күренекле кешеләрнең берсе булып тора. Ихтимал, Шакуловлар нәселеннән бүгенге көндә тагын да вәкилләр бардыр, аларны барлау кирәкле эш.

Сәйедләрнең нәселләре бүгенге Русиянең һәм башка дәүләтләрнең шәһәрләрендә яшәгәннәр. Мәсәлән, Казан шәһәрендәге Яңа бистә зиратында бер кызыклы кабер ташы язмасы шул хакта сөйли. Аны фотожурналист Ибраһим Галиев 1961 елда фоторәсемгә төшереп алган булган. Ибраһим ага 1970 елларда бу ташның фоторәсемен безгә бүләк иткән иде. Аның йөзлегендәге язманың хәзерге әлифкә күчермәсен бирәбез:

> «Мәркадел-гарәб*
> Корайыш кабиләсе
> Һашим ыругының
> әш-шәйех Габдулла
> бине әш-шәйех Габдес-
> сәлам 1280 сәнә
> вафат, 44 яшендә».

Таш бүгенге руми хисап белән 1874 елда язылып куелган. Димәк, XIX гасырның икенче яртысында Казан шәһәрендә дә сәйедләр яшәгән булып чыга. Бәлки, аның нәселләре бүгенге көндә дә Казанда яки Татарстанда яшиләрдер, сәйедләр нәселен дәвам итүчеләр бардыр әле. Югарыда китерелгән мәгълүматлар сәйедләрнең Мөхәммәд пәйгамбәр нәселеннән килгән дин эшлеклеләре булуларын һәм шушы фамилиядән (ыруудан) булган берсенең дәүләт яки өлкәләрнең төп дин башлыклары икәнлеген белдерәләр. Сәйед сайланып куела торган урын түгел, ә нәселдән килә торган рухани дәрәҗә.

Без Касыйм ханлыгы дәвереннән бирле килгән сәйедләр нәселе шәҗәрәсенә бер тарихи күзәтү ясадык. Бу нәсел тарихына кагылышлы яңа мәгълүматлар да табылу мөмкин. Аларны барлау, туплау милли тарихыбыз чыганакларын ачыклау юлындагы күркәм эшләрнең берсе булыр иде.

ИСКӘРМӘЛӘР

[1] Исхаков Д. Татар дәүләтләрендә сәетләр // Ватаным Татарстан.— 1995.— № 13.— 21 гыйнвар; Мөхәррәмов Ә. Бездә сәетләр бармы? // Шәһри Казан.—1995.— № 18.— 28 гыйнвар.

[2] История Татарии в документах и материалах.— М., 1937.— С.99.

[3] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства.— М., 1991.— С.196—197.

[4] Худяков М. Очерки… — С.69, 72.

[5] Атласи Һ. Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы. — Казан, 1993.—145 б.

[6] Тарихчы М.Г.Худяков Мансурны Хаҗитархан (Әстерхан) сәйеде дип күрсәтә (Худяков М. Очерки… С.105).

[7] Әхмәтҗанов М. Шагыйрь Шәриф Хаҗитархани // Шәһри Казан.— 1995.— 28 июль.

[8] Борынгы татар әдәбияты.— Казан, 1963.— 354—355 б.

[9] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах.— СПб., 1864.— Ч.II.— С.443.

[10] Гарәп телендәге фразалар татарчага тәрҗемә итеп бирелә.

[11] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование…— Ч.II.— С.443.

[12] Шунда ук.— 93 б.

[13] Шунда ук.— 443 б.

[14] Шунда ук.— 444 б.

[15] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование...— СПб., 1866.— Ч.III.— С.498.

[16] Шунда ук. — 497 б.

[17] Вельяминов-Зернов В.В. Исследование... — СПб., 1887.— Ч.IV.— Вып. 1.— С.3.

**Резюме**

Публикация М.И.Ахметзянова посвящена генеалогическим памятникам сеидов Касимовского ханства. Эти шеджере находятся в Хранилище рукописей ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова АН РТ.

***Нурулла Гариф,***

Татарстан Республикасы
язучылар берлеге әгъзасы

## КОЛ ШӘРИФ ТУРЫНДА ТАРИХИ МӘГЪЛҮМАТ БИРҮЧЕ ЧЫГАНАКЛАРГА ҺӘМ ӘДӘБИЯТКА КЫСКАЧА БӘЯЛӘМӘ

Казан ханлыгы тарихы һәм шул исәптән Кол Шәриф мулла шәхесе язмышына бәйле тарихи мәгълүматларның зур љлешен тарихчылар «Патша китабы» яисә «Никон елъязмасы» дип аталган урыс чыганакларына таянып язалар. Аның атамасы XVII гасырда яшәгән китап белгече патриарх Никонга бәйле. Никон елъязмасының язылу вакыты һәм урыны тљгәл билгеле түгел. Әлеге елъязмаларны тикшерүче М.Н.Тихомиров билгеләп үтүенчә, елъязмадагы XVI гасырга бәйле тарихи вакыйгалар, икенче тапкыр күчерелеп язылганда, шул чордагы сәяси вакыйгаларга бәйле үзгәреш кичергәннәр. «Патша китабы» — Явыз Иван яшәгән чорга бәйле тарихи язмалар тупланмасы. Алар күп очракта бер-берсен кабатлый.

Икенче чыганак А.М.Курбскийның «Казан алынуы турында хикәя» дип атала. Аның авторы 1552 елда Казанны алуда һәм 1554 елда ханлыкта дәвам иткән халык күтәрелешләрен бастыруда катнашкан гаскәр башлыгы, Явыз Иванның якыннарының берсе. Курбский 1563 елны Ливон сугышында гаскәрләреннән күпкә ким гаскәргә юлыгып җиңелә. Бу вакыт Явыз Иванның бар боярлардан, үзенең элеккеге яраннарыннан үч алу чорына туры килгәнлектән, Курбский да алар тәкъдиренә тарачагын аңлый. Шунлыктан «Олуг кенәз» ачуыннан куркып, 1563 елны, хатыны белән улын ташлап, Литва кенәзлегенә кача. Үзен гаепле сизми, дусларына, Явыз Иванга язган хатларында: «Мәскәү кенәзенең явызлыкларын күп ишеттем, үзем дә күрдем...» — ди. Мәскәү кенәзе турындагы хатирәләре дә шунда язылган. Ул анда Иванның бар явызлыкларын фаш итә. Безнең љчен аның Казанны алу турындагы хикәяләре игътибарга лаек. Ул анда күп очракта үзе күргәннәрен яза, шул чордагы Казан шәһәрен күзаллауга ачыклык кертә. Курбский тарафыннан казанлыларның, Ватаннарын саклап, батырларча сугышулары тәфсилле яктыртыла. Хикәясендә башкалардан ишеткәннәре дә бар. Бәлкем, башка чыганакларны да кулланггандыр. Мәсәлән, ул Кол Шәриф һәм аның шәкертләре мәчет-мәдрәсәләр янында урысларга каршы каты сугышып, барысының да бердәм шәһит китүләрен күрә алмый. Бу вакытта ул Нургали капкасы ягындагы тау астында була.

Љченче чыганак Казан ханлыгы тарихына багышланган «Казан елъязмачысы» китабы. Елъязма 1564 — 1565 елларда язылган. Аның авторы, 1532 — 1551 елларда Казанда әсирлектә булып, Казан ханнарына хезмәт иткән. Шул чорда Казан тарихы белән танышкан. Елъязмачы, Казан тарихын бәян итүдән бигрәк, Явыз Иванның «кылган батырлыкларын» мактауга алына. «Бљек» җиңүләрнең тарихын кәгазь битләренә тљшергәндә, үткәннәр белән горурланып, киләчәк буыннарның күңелен уйнатырлык тљсләр кызганмый. Әсәрдә башыннан ахырынача шовинистик рух, Казан халкына нәфрәт белән карау бљркелеп тора. Елъязмачы вакыйгаларның барысын да үзе күргән кебек сүз йљртсә дә, язманың соңрак чорда кем тарафыннандыр үзгәртелүен күрү кыен түгел. Аны язганда бары бер генә таләп куела: «Урыс халкының бљек җиңүен мәңгеләштерү». Автор моны үзе дә яшерми. Бу җиңүгә багышлап Казанда «һәйкәл кую» да тарихи елъязмада беренче тапкыр чагылыш таба, бернichә урында искәртелеп узыла. Казан ханлыгы тарихы җиңүчеләр күзлегеннән генә бәян ителсә дә, елъязма тарихи чыганак булып кала бирә.

Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мљстәфадел-әхбар...» дигән китабында (икенче томда) Казан каласындагы сигез манаралы мәчетне искә ала. Бүгенге кљндә аны Кол Шәриф мәчете атамасында йљртәләр. Бу һәм башка мәгълүматларның нинди чыганакларга таянып язылганы әлегә тљгәл билгеле түгел. Без искәрткән урыс чыганакларыннан башка татар телендәге язма риваятьләр кулланылуы да мљмкин.

Мәрҗанидән соңгы тарихчылар Кол Шәриф шәхесенә бәйле тарихны әлеге язма чыганакларга таянып язалар. Тљрле яңалыклар кертү аларның шул чорга анализ ясап, күзаллауларына бәйле. Кол Шәриф шәхесе дин башлыгы, Казан — Мәскәү арасындагы дипломатик очрашуларны алып баручы, илче, Казан шәһәрен саклауны оештыручы җитәкчеләрнең берсе буларак та яктыртыла. Соңгы чорларда язылган әдәби әсәрләрдә дә Кол Шәрифнең еш искә алынуы игътибарга лаек. Бу эшчәнлек халкыбызның бай тарихын кайтару, милли бердәмлеккә туплап, аңа рухи азык бирүдә зур этәргеч булып тора.

## КОЛ ШӘРИФ ШӘХЕСЕНӘ БӘЙЛЕ ТАРИХИ ИСТӘЛЕКЛӘР

**ПСРЛ.— Т.13. Патриаршая или Никоновская летопись.— М., 1904.**

**с.468**

...Казанцы почали посылати к Шигалею и к воеводам бити челом, что бы государь пожаловал, гнев свой отдал им, а пленити их не велел, а дал бы им государство царя Шигалея, а Утемеш бы гирея царя государь к себе взял и с матерью Сююнбика-царицею; а приеждял с тем ко царю и воеводам Кулшариф-молна да Тюменский князь Бибарс Растов… срок им учинили не воевати дватцать день.

**с.469**

Августа в 14 день приехал ко царю и боярам Кулшариф-молно и Маамет-сеит, Майсыр-сеитов сын, и все с ним шихи и шихзады, имамы и молозаде и один и дербыши, да Кудайгул-улан, а с ним улоны все, да Муралей-князь, а с ним многие князи и мурзы; и бояре велели им честишертную грамату, на чем государь пожаловал и как им вперед быти. И они все столи о Горей стороне говорити, что того им учинити не можно, что земля розделити…

**с.201**

...Царь благочистивый посылает грамоты к Кулшариф-молны и ко всей земли Казанской, чтобы государю били челом, а кто лихое дело почал и землю возмутил и на государя и бояр его лихое дело возвели, за тех бы не стояли, и государь их пожалует...

**с.202**

...И тут приехал к государю служит Камай мурза, княж Усеинов сын, а с ним 7 казаков; а сказывал государю, что было их поехало человек с двести к государю служити, сведов Казанцы иных переимали. А про Казань государю сказывал в городе царь Едигер-Магмет советом злым с Казанце утвердилися, а государю бит челом не хотят; единомышленников его Кул Шариф молна и кады да Зейнеш князь Нагайской, да изменники государевы Чапкун-князь — тот аталык у него — да Ислам-князь, Аликей Нарыков, Кебек князь Тюменский, Дербыш-князь: те всю землю на лихо новодят; и запасы в городе многие; «а совет их: послали на Арскую засеку твоих же государевых изменников Япанчу-князя да Чапкунова племянника Шунак мурзу да Арьского князя Явуша, а велел к засеке всех людей собрати, которые не в городе, и приходити на государевы люди и за засеку бы войнских людей на Арское не пропустить».

**с.218**

И приближа христиане к мечете к Кул Шарифу к Тезицкому врагу, и тут с Кул Шарифом-муллою многие неверные совокупишиеся и зле бьющиеся,— убиша Кул Шарифа с его полком-Божьем милосердием одолеваху провасловие Кул Шарифа, с всеми его побиша.

**Курбский А.М. История о великом князе Московском.— М., 2001.**

**с.57**

Когда же в город внезапно вошло свежее войско, облачённое в светлые доспехи, то царь казанский со всем своим воинством начал отступать назад, крепко держа оборону, но наши неотступно бились с ними и прогнали войско казанского царя аж до мечетей, что вблизи его двора стоят, и встретились там с их обызами, сеитами и молнами и с их великим епископом, а по их языку амиром по имени Кул Шариф-мулла, и сразились они с нашими так сильно, что все до единого погибли.

**Казанская история / Пер. Т.Ф. Волковой.— М., 1985.— С.301—539.**

**…О жестоком ответе казанцев царю и великому князю.**

**Глава 61**

...Послов же самодержавца с позором прогнали они от города,облаяв их жестоками славами. И, вознесясь в гордости своей и высокомерии, раня и раздражая сердце его, говорили они так: «Узнай же, царь московский, что отвечают тебе царь и все казанцы: лучше умрем мы все до единого с женами с нашими и с детьми за законы, и веру, и обычая отцов своих здесь, в отечестве нашем, в котором родились, и в городе нашем, в котором выросли и живем тепер, и в котором царствуют цари, которыми управляют уланы, и князья, и мурзы! Ты же и так богат и много имеешь городов и земель, а у нас один только стольной город Казань, и тот, придя к нам, хочеш ты у нас отобрать, почуствовав свою силу над нами.

Не мечтай же и не надейся, обманывая нас угрозами, что возьмешь царство наше. Уже ведь познали мы лукавство ваше и нехотим ни за что по доброй воле сдать город наш, пока все не умрем. И не видеть бы нам и не слышать того, что русскими твоими людьми, погаными свиноядцами, населен и управляем стольной город наш Казань, и добрые наши законы вашими ногами попраны и осмеяны, и установлены в нем русские обычаи».

**Собирание всех убитых в Казани казанцев и русских воинов, очищение города.**

**Глава 86**

Когда же кончилась битва. И смолки крики, и улеглось волнение, повелел царь великий князь искусным умельцам, объехав город, собрать в одно место и сосчетать, сколько убито казанцев и русских. И, быстро поездив, собрал всех и сосчитал рязанский воевода Назар Глебов, ибо был он умен и искусен в счете... Сосчитал он и доложил: «Побито,— сказал он,— самодержец, более ста девяноста тысяч казанцев, детей и взрослых, старых и молодых, мужчин и женщин, и все это — не считая пленных, тех же число еще больше». Царь же покачал головою и сказал: «Во истину эти люди, дерзкие и неразумные, стойкими были и мужественными и умерли свободными, не покорившись моей воле». Русских же воинов, убитых казанцами во время всех приступов и в стычках во время вылазок, насчитали пятнадцать тысяч триста пятьдесят пять человек.

И повелел царь великий князь пехотинцам вычистить город, и царский двор, и все улицы, и площади и вытащить вон из города трупы всех убитых казанцев, и побрасать их далеко за городом, в пустынном месте, на съедание псам и зверям и на расклевание птицам небесным. Среди трупов нашли и убитого казанского сеита и того наглого варвара, что был лазутчиком и изменником,— князя Чапкуна...

**Мәрҗани Ш. Мљстәфадел-әхбар...— Казан, 1989.**
**199 — 200 б.**

«Россия, 961 (1552) ел ахырында татарларны җиңеп, Казан шәһәрен һәм аның тирә-юнен яулап алганда, кальга эчендә сигез манаралы бер җәмигъ (баш) мәчет, «таҗик ермагы» дип йљртелгән урында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә була. Галимнәрдән, хљрмәткә лаек габбасилардан һәм бљек сәйедләрдән күпмедер шәхес булып, аларның башында нәкыйбел-әшрәф (бљекләрнең җитәкчесе) дип танылган мелла Шәрифкол исемле бер зат тора. Ул ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирамга һәм зур хљрмәткә ия була.

«Россия кенәзләре, Казан ханнарына илчеләр аша хатлар күндергәндә, мелла Шәрифколга да махсус хат һәм бүләкләр җибәрә иделәр» дип сљйлиләр. Ахырда, россиялеләр Казанга һљҗүм иткәндә, ул, үзенең иярченнәрен җыеп, мәдрәсәгә керә һәм, мәдрәсә түбәсенә чыгып, россиялеләр белән бик каты сугыша. Руслар аны мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп тљшерәләр һәм ул шулай итеп шәһит була...

**Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства.— М., 1991.**
**с.134**

После бегства крымского гарнизона дни крымской династии на казанском престоле были уже сочтены. Власть перешла к сторонникам мира с Россией. В Казани образовалось временное правительство, во главе которого стали оглан Худай-Кул и князь Нур-Али Ширин (сын князя Булата). Новое правительство немедленно вступило в мирные переговоры, и в Свияжск была отправлена депутация — глава духовенства Кул Шариф и князь Бибарс Растов, приглашать Шах-Али на престол. Шах-Али заключил с казанцами перемирие на 20 дней и предложил отправить послов в Москву.

**с.137**

Курултай 14 августа 1551 года. Проект присоединения Казанского ханства к России. 13 августа Шах-Али и русские воеводы высадились на устьи Казанки, в 7 верстах от Казани. Хан послал в город своих дворецкого и конюшего с имуществом приготовить дворец. 14 августа на устьи состоялось народное собрание-курултай, которое должно было выразить волю всего государства по вопросу о горной стороне. В собрании принимали участие следующие группы казанского населения: 1) духовенства — Кул Шариф сын сеида Мансура, шейхи, шейх-заде, муллы, муллы-заде, хаджи и дервишы, 2) огланы во главе с Худай-Кулом, 3) князья и мурзы, с Нур-Али сыном Булата Ширин во главе.

**с.148**

Правительство при хане Ядыгаре составилось из следующих лиц: Кул Шариф, кади, князь Чапкун Отучев, кн. Алике Нарыков, ногайский князь Зениет, сибирский князь Кебек и кн. Дервиш.

**с.153**

Отчаянный бой произошел у главной мечети Кул Шарифа, на Тезицком овраге Кул Шариф пал в бою.

**с.298**

Своими архитектурными формами Василий Блаженный больше всего напоминает мечеть Кул Шарифа в Казани, с ее 8 минаретами, предание о которых записано Марджани. Восемь башен Василия Блаженного, увенчанное восточными куполами и размещенные вокруг центрального шатра, находят себе порази-

тельное соответстие в этих 8 минаретах. Таким образом, предание, записанное Марджани, косвенным образом получает реальное потверждение, и мы можем составить хотя бы приблизительное представление об этой сложной композиции с 8 минаретами. Отсутствие главного фасада, составляющее главную черту татарского зодчества, также имеется налицо в Василии Блаженном. Недаром строителем храма являлся тот архитектор, Постник Яковлев, которому было поручено сооружение каменной крепости покоренной - Казани, и который мог таким образом на месте ознакомиться лично с памятниками казанской архитектуры. Если эти соображения найдут себе потверждение, то самая идея постройки получит новый, более глубокий внутренный смысл.

**Атласи Һ. Себер тарихы. Сљенбикә. Казан ханлыгы: Тарихи әсәрләр.— Казан, 1992.**

**156 б.**

Казанга хан буларак Шәехгалине җибәрүен, Сљен-бикә илә Үтәмешгәрәйне Мәскәүгә алдыруын үтенделәр.

Бу хәбәрне Шәехгалигә китерүчеләр Казанның иң атаклы галимнәреннән булган Кол Шәриф мулла илә Бибарс Растов исемле кеше иде. Шәехгали, Казан илчеләре илә сљйләшкәннән соңра, аларга олуг кенәз Иванның үзе янына илчеләр җибәрергә, аңа багындыкларын белдерергә боерды. Эшне эшләр љчен 20 кљн миһләт куеп, шул арада Казан љстенә йљрми торырга сүз бирде. (Никоновская л., т.5, с.167; Царственная кн., с.468.)

**164 б.**

Сљен-бикәнең Зљядән китүеннән бер кљн соң Шәехгали Казанга китте. Казан елгасының тамагында кљймәдән тљшеп, Бишбалта янында урын тотты. Августның 14 нче кљнендә Казаннан Кол Шәриф мулла, Мљхәммәтсәед, Ходайкол углан, Мурали бәкләр Шәехгали янына килделәр. Болар Шәехгалине Казан ханлыгына билгеләр, урыслар илә ике арада булачак эшләрне сљйләшер љчен килгәннәр иде. (Никоновская л., т.5; Царственная кн., с.470.)

**389 б.**

Иван, Казан љстенә баскынлык иткәнчегә чаклы, анда кеше җибәреп, сүз алышуны тиешле тапты. Казанлыларга җибәреләчәк язуда, әгәр дә алар үз ирекләре белән килеп Иванга багынсалар, Иван аларның гљнаһларын багышлаячак икәнлеге язылган иде. Шәехгалинең Ядкәр белән якынлыгы булганга, Иван аңа, Ядкәрне үзенә баш бирергә димләп: «Син олуг кенәздән куркырга тиешле түгел; әгәр дә син Иван янына килеп, аңардан үзеңне багышлауны үтенсәң, ул сине багышлаячак»,— дип, ханга хат язарга боерды. Иван, Кол Шәриф муллага, шулай ук Казан кешеләренә язу язып, аларны котыртучыларның сүзләренә карамаска, үзенә килеп багынырга димләде. (Бархатная книга, т.1, с. 243—251.)

**419 б.**

Ядкәр хан мәсҗедләр янына якынлашкач, Казанның голямасы, урысларга каршы чыгып, аларга һљҗүм итте. Боларның арасында шәһәрнең абызлары, сәйедләре, муллалары булып, башлыклары Казанның иң атаклы галимнәреннән булган Кол Шәриф мулла иде. Казан голямасында дини һәм милли тойгылар яхшылап уянмаган, шуңа күрә алар Казан халкын кирәгенчә тәрбия итә алмаган иде исә дә, аларның бу эше үзләренең һәм борынгы бабаларының гљнаһларын багышлатыр љчен иң изге бер эш булды. Болар, урысларның кљчле гаскәрләренә күкрәк киереп, һичнәрсәдән курыкмаенча орышка кереште. Бер тљркем Казан муллаларының һљҗүме белән генә урысларны кире чигерү мљмкин түгел иде исә дә, бу эш тегеләрнең борынгы гљнаһларын ярлыкатыр љчен зур бер эш булды. Болар, тоткын булып яшәүгә караганда, Йорт љчен үлүне артык күргәннәр, шул уй белән орышка керешкәннәр иде. Аларның уйлары үзләренчә изге булган кеби, үлүләре дә изгеләрчә иде. Боларның барысы да урыслар кулыннан үтерелеп, берсе генә дә сау калмады. (Никоновская л., т.5, с.218; Царственная кн., с.513; Татищев В.Н., т.5, с.367; Сказание князя Курбского, с. 33.)

**Казан ханлыгының соңгы кљннәре**

**Зәки Вәлидинең «Тљрек вә татар тарихы»ннан // Мирас.— 1992.— № 10.**

**23 б.**

Кљннәр бик яңгырлы һәм пычрак иде. Руслар коралларын кљймәләреннән бик авырлык белән генә чыгардылар. Бу вакыт Казан эченнән Камай исемендә бер мирза, Иван янына килеп, Казан эчендәге барлык эшләр турында сљйләп бирде: «Без, 200 ләп кеше, Русиягә шул килеш кенә бирелүне теләдек, алар безнең һәммәбезне тотып алдылар. Мин ялгызым качып котылдым. Ядкәр хан, галимнәрнең башлыгы мулла Кол Шәриф, Иртыш мирза, Чапкын, Аталык, Ислам, Галекәй, Нарыйков, Кибек исемендәге мирзалар халыкны Русиягә каршы чакыралар. Казанда 30 меңлек Казанның үз гаскәре, 2700 Нугай гаскәре бар. Беркадәр гаскәр белән Япанчы мирзаны, гаскәр җыю љчен, Арча тарафына җибәрделәр. Казанда солых теләүче берәү дә юк...» — дип сљйләде.

**26 б.**

Руслар зур мәчет янына килеп җиттеләр Бу урындагы мәдрәсәдә бик күп шәкертләр бар иде. Галимнәр башлыгы — шәйхелислам мулла Кол Шәриф тә шунда иде. Барлык шәкерт һәм галимнәр бердәм русларга һљҗүм иттеләр, бик күбесе һәлак булды. Мулла Кол Шәриф беркадәр шәкертләр белән мәдрәсә љстенә менде, шуннан торып руслар белән каты сугышты. Руслар, мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп тљшереп, барысын да үтерделәр.

**Татар әдәбияты тарихы.— Казан, 1984.**
**294 б.**

Казанның үзендә генә Гарифбәк, Кол Шәриф, Мљхәммәдшәриф, Касыйм шәех кебек әдипләр, шагыйрьләр, галимнәр яшәгән...

Профессор Г.Сәгъди татар культурасы тарихында исемнәре билгеле булган Кол Шәриф белән Касыймны «Бакырган китабы»нда шигырьләре теркәлгән бер үк кешеләр итеп, татар шагыйрьләреннән саный.

Рус елъязмалары Кол Шәрифне Казан белән Мәскәү арасында барган катлаулы дипломатия эшләрендә катнашкан йогынтылы һәм дәрәҗәле рухани җитәкчеләрдән хисаплый. Мәсәлән, ул 1551 елның августында Казаннан Мәскәүгә барган илчелекнең җитәкчесе булган һәм патшага үтенү ярлыгы тапшырган. Иван IV, Зљя каласына килгәч, конфликтны тыныч хәл итү турындагы тәкъдим грамотасын Казанга Кол Шәрифкә күндергән. (ПСРЛ, т. 13. Патриаршая или Никоновская летопись, М., 1965, с. 201.)

**Алишев С. Казан ханлыгының тормышы һәм һәлакәте // Мирас.— 1993.— № 10.**
**58 б.**

...Урыс гаскәрләренең Кремльгә керү юлында — Таҗик чокыры янында — Кол Шәриф мулла оештырган һәм коралландырган бер тљркем руханилар, мулла-мљдәррисләр һәм шәкертләр киртә булып торган. Алар барысы да шунда соңгы тамчы каннарынача сугышканнар. Воеводалар шуннан соң гына кљнчыгыш яктан Кремльгә керә алганнар. Кол Шәриф алаеның бу каһарманлыгы Ядкәр ханга хан сарае урнашкан җирдә — кайсарда (цитадельдә) ныгып урнашырга мљмкинлек биргән. Бу соңгы урында Ядкәр хан җитәкчелегендәге 6 меңләп гаскәри — Казанның соңгы сакчылары булган.

**Рорлих А.-Г. Казан ханлыгы // Мирас.—1992.— № 10.**
**48 — 49 б.**

Сәет љстенлек итүче дини власть, дини учреждениеләр җитәкчелегендә торды. Ислам традициясе буенча ул пәйгамбәр нәселеннән булырга тиеш иде. Сәеттән соң дәрәҗә буенча шәехләр (љлкән ислам галимнәре), имамнар һәм муллалар бара. Тулаем алганда дини оешма Казан җәмгыятендә җир биләүдә мљһим элемент иде. Шуңа күрә кайбер авыл исемнәре, әйтик, Сәетова, Кулсәетова, Ходяшево, Дербышка, аларның биләүчеләрнең рухани кешеләр булганлыгын искәртә.

1513 елда язылган Тәфсир кебек Коръәнгә комментарийлар Казанны Ислам гыйлемлеге һәм белемлеге үзәге итеп ачык рәвештә күз алдына китерәләр. Казан ныгытмасында гына биш таш мәчет һәм байтак мәдрәсәләр бар иде; Кол Шәриф һәм Нургали мәдрәсәләре күзнең явын алырлык иделәр. Сигез манара белән бизәкләнгән Кол Шәриф мәчете иң биеге иде һәм, мљгаен, баш мәчет булып хезмәт иткән.

**Трепавлов В.В. История Ногайской Орды.— М., 2002.**
**с.255**

Из Казани шли вести, что ... в городе царь Едигер—Магметь сеитом злым с казанцы утвердилися, а государю бить челом не хотят; а единомышлеников его Кул Шариф молна и кады, да Зейнешь князь ногайской... всю землю на лихо наводять». (Патриаршая или Никоновская летопись / Редактор С.Ф.Платонов.— СПб., 1904 // ПСРЛ. Т.13. Ч.2, с. 202.)

**Латыйфи Ф. Хыянәт.— Казан, 1993.**
**169 б.**

...Аллаһы Тәгалә куәт вә мәдәт бирсен!

...Кол Шәриф каурый каләмен кљмеш кара савытына батырды да күзләрен бер ноктага текәп уйга калды, авыз эченнән генә дога укып битен сыпыргач, янәдән иртәдән бирле тынгы бирмәгән уйларын, чуалган зиһен җебен сүтәргә кереште.

Кол Шәрифне куандырганы шул — тәхетне ныгытуда аның љлеше аз булмады. Алтын-кљмеш чыңыннан колаклары томаланган малтабарларның күңеленә барып җитәрлек, зиһеннәрен уятырлык сүзләр табарга, күзләренә ачык дәлилләрне үтемле итеп күрсәтә белергә дә кирәк иде бит. Иншалла, ахыры хәерле

булсын, Казан халкы аның сүзенә битараф түгел, әйткәне бер колактан кереп икенчесеннән чыкмый, биләр-морзаларның аңында да, гади халык күңелендә дә урын таба.

Әле ир уртасы яшенә җитмәсә дә, инде галимнәрдән дә нәкыйбел-әшраф дип танылган галиҗәнап мелла Шәрифкол сигез манаралы җәмигъ мәчетнең беренче хатибы, гыйлемле вә белекле, белкевар дигән югары исемгә лаек затлардан да беренчесе иде. Аксљяк угланнарга вә дәхи гади халыктан чыгып, тырышлыгы, зирәклеге белән башкалардан аерылып торучы, гыйлемлек эстәүче яшь егетләргә сабак укыту белән бергә, ул мәмләкәтнең иң кадерле, иң асыл хәзинәсенә ия кеше. Чљй язуы белән чуарланган таш такталарны да, ерак Рум галимнәренең серләрен теркәгән, бозау тиресеннән тегелгән калын китапларны да, уйгур, чин һәм гарәп хәрефләре белән сәйләндәй тезелгән йљзләрчә битле елъязмаларны, күтәрә алмаслык алып китапларны да табарга була аның хәзинәсендә. Алар арасында да иң кадерлесе — борынгы бабаларыбызның шәҗәрәсе — ерак-ерак гасырлар тљпкеленнән килгән изге язмалар саклана монда.

Кол Шәрифнең инде күп еллар элек үзенә кагыйдә иткән бер гадәте бар: ил-кљндә чуалышлар, хљкемдарлар арасында сәбәпсез ызгышлар кузгалса яисә күңелендә шом-шљбһә уянса — китапханәнең аскы катындагы хљҗрәгә кереп бикләнә, калын китапларның дәверләр кичүдән тоныкланган кљмеш каптырылмаларын ычкындыра да борчыган сорауларына, күңелен бимазалаган шикләргә җавап эзли.

— И борынгы тљрки бабаларыбыз! Киңәш бирегез, ни кылыйм? Мәмләкәтнең авыр кљннәрендә котылу юлын каян эзлим?..

— Әйтегезче, чин, рум, Мисыр һәм уйгурның белекле адәмнәре, сезнең тарихта моңа охшаш хәлләр булдымы? Булса, чыгу юлын ничек таптыгыз? Ахыры ни белән бетте? Киләчәк буыннарга кисәтү-киңәшләрегезне кайларда язып калдырдыгыз, нинди сүзләргә, тылсымга тиң гыйбарәләргә тљреп яздыгыз?

Китап — ул хәтер. Теге яки бу халыкны юк итим дигән илбасар, залим хљкемдар иң элек аның китабын, язуын бетерер, яндырыр, кљлгә әйләндерер. «Хәтерсез кеше — хайван мисалында,— дип љйрәтә аларны белкевар,— хайван ни эшләткәнгә дә риза, муенына бау тагып сатарга алып барганда да, бәйләп суярга салганда да, чәйнәренә ризыгы, күшәренә чүбеге булса — аңа шул җиткән. Сез — адәм затыннан. Хайван хәленә тљшәсегез килмәсә, укыгыз, белем җыегыз. Белем алу — энә белән кое казудыр. Аның башка юлы юк. Адәми зат дигән кешегә тырышып, күз нурыңны коеп кына ирешеп була».

Кол Шәриф йокламый, йоклый алмый. Дљньяны борчулы уйлар басты. Алар тынгылык бирми, кљнен дә, тљнен дә миен бораулый, ике чигәсен авырттырып кыса, диван әһелләреннән, бљтен ханлыкның акыл ияләрен ала алмаган җавапны каян табарга кирәклеген эзләп бәргәләнергә мәҗбүр итә. Бабаларыбызның сыеныр, туеныр урыны — газиз җиребезне, ил-кљнебезне, Аллаһы Тәгалә рәхмәте илә Мәхәммәт галәйһиссәламгә согынган илдәшләребезне ни кљтә?!

«Йа Алла! Сабырлык, түземлелек бир! Белгәнеңне, сизенгәнеңне теш арасына кысып чыдарлык кљч бир! Кара тљннәргә уралып галәм фасыллары үтәр дә китәр, якты кљннәр туар. Этләргә каласы Казан алардан арыныр, бетмәс, чорлар, томаннан яктырып, ялтырап, яңадан күтәрелер, койрыклы йолдыз шикелле эзсез янып югалмас, галәм әйләнешенең яңа фасылында кљлдән үсеп чыгар. Чљнки кальга астына эт салынса, мәчет астына тегермән ташы салынган. Этләр үләр дә бетәр, таш калыр. Амин!»

**Резюме**

Аспирантом Института истории АН РТ Н.Гарифом собран интересный материал о жизни и деятельности поэта Кул Шарифа, извлеченный из русских летописей, произведений князя А.Курбского и русских историков М.Худякова и В.Трепавлова, а также из трудов татарских ученых Ш.Марджани, Х.Атласи, З.Валиди, С.Алишева, А.-А. Рорлих, А.Шарипова, писателя Ф.Латифи.

***Дамир Исхаков,***

доктор исторических наук

## Сеиды в Казанском ханстве

Наиболее раннее упоминание о казанских сеидах встречается в послании Ивана III тюменскому хану Ибрагиму (1489 год). Там сказано: «... а нашего недруга Алегамовы (хана Ильгама.— *Д.И.*) люди царевы, которые от нас бегают, Алказый, да Тевеккель сеит, да Касим сеит, да Бегиш с сыном с Утешом и иные их товарищи, и тех людей Ивак царь ..., мыр-

зы у себя держат»[1]. В этом сообщении речь идет о высшей знати Казанского ханства времени правления хана Ильгама (1473 — 1487). Алгазый, возможно, являвшийся мангытом[2], был «князем» и оказал ожесточенное сопротивление русским при их походе на Казань в 1487 году[3]. По сообщению ногайского мурзы Ямгурчея, «князь» Алгазый из Ногайской Орды уехал в Тюменское ханство: «... Алгазыя яз не видал, с Ибраимом царем к Тюмени поехал, от тех мест у Ибреима царя в Тюмени живет»[4]. Бигиш, бывший также «князем», принадлежал к клану Ширинов[5]. По сговору с казанским ханом Мухаммад-Эмином Иван III в 1491 году собирался этих людей заманить к себе[6], что ему, скорее всего, удалось сделать[7]. Имя Тевеккель сеида после 1489 года в документах больше не встречается, поэтому неизвестно, что с ним стало. А вот Касым сеид упоминается и в 1490—1491 годах[8]. Он еще в 1491 году находился в Ногайской Орде. Мурза Муса об этом пишет Ивану III: «Касым сеит нынечя у нас живет»[9]. Согласно данным указанного мурзы, сеид Касым хотел вернуться на свою родину: «... у тебя (т.е. Ивана III.— *Д.И.*) просим, царю (хану Мухаммад-Эмину.— *Д.И.*) молвя, чтобы ему (Касыму.— *Д.И.*) на его юрт ити»[10]. Но ему вряд ли удалось вернуться домой: когда Иван III через своих послов приглашал Алгазия, Бегиша с сыном Утешем и сеида Касыма «ехати» к себе, он одновременно тайно договаривался с ханом Мухаммад-Эмином о том, что оставит их у себя, «чтобы они не были у ... недругов»[11]. Мое предположение подкрепляется еще и тем, что князь Утеш к 1509 году находился в руках московского великого князя Василия[12].

Можно допустить, что сеид Тевеккель, явно имевший старшинство перед сеидом Касымом — в документе за 1489 год сначала назван именно он — в годы правления хана Ильгама являлся главой казанского духовенства. Лишь после исчезновения из поля зрения вначале сеида Тевеккеля, а затем и сеида Касыма, в русских источниках появляется имя нового сеида.

Это был сеид Бораш (Бараш, Бураш), фигурирующий в 1492 году в качестве ханского посла в грамоте казанского хана Мухаммад-Эмина Ивану III[13]. Похоже, что он был не просто послом, так как в 1491 году сеид Бораш отмечен в составе войск казанского хана, совместно с русскими войсками пришедшими на помощь крымскому хану Менгли-Гирею во время его борьбы против Большой Орды[14]. Как явствует из летописного сообщения, Бораш сеид в походе участвовал как один из двух воевод (аналогия с Касимовским ханством). В 1497 году он опять выступает в роли посла: «А послаша князи Казанския Бараш-Сеита ... на Москву бити челом от них и от веса земли ...», чтобы «... государь князь великий ... пожаловал, ... и нарек ... на царство в Казань Абдыл-Летифа царевича»[15]. Приведенные данные позволяют высказать предположение о том, что рассматриваемый сеид являлся крупной политической фигурой. Иначе трудно объяснить причину того, что именно ему доверили ведение переговоров от имени «всей земли» о новом казанском хане. А переговоры он провел успешно[16]. В 1507 году, в очень сложных политических условиях, Бораш сеид еще раз участвовал в переговорах «о миру, о братстве и о дружбе» с Москвой в качестве посла хана Мухаммад-Эмина[17]. Добившись успешного завершения переговоров, 8 сентября 1508 года он из Москвы выехал в Казань[18]. После этой даты его имя в источниках больше не появляется. Но говорить о его кончине около 1508 года я считаю преждевременным, как и о его статусе. Данный вопрос необходимо рассмотреть более детально.

Гадәттә, татарлар Мәскәү мәмләкәтенә кертелгәннән соңгы татар әдәбиятын XVI гасырның урталарыннан, ягъни Казан ханлыгы бетерелгән дәвердән башлыйлар. Гомумән дљрес булган мондый караш янә бераз љстәмә ачыклык кертүне сорый. Мәгълүм булганча, Казан һәм Әстерхан ханлыклары 1552 — 1556 елларда тәмам юк ителә. Клњбатыш Себердәге татар мәмләкәте мондый язмышка 1585 елда дучар була. Кырым татарлары исә үз дәүләтчелегеннән 1783 елда гына мәхрүм ителәләр. Курчак хљкүмәт рәвешендә булса да, Касыйм ханлыгы да 1682 елга кадәр яши әле. Шактый халкын безнең әби-бабаларыбыз тәшкил иткән Нугай Урдасының да, Казан дәүләте бетерелгәннән соң, гасырдан артык яшәве мәгълүм.

XV йљзнең урталарында дљньяга аваз биргән татар ханлыклары үзләренең туулары белән барысы да Алтын Урдага бурычлы. Җучи улусы — аларның тљп йорты, ата-анасы һәм әби-бабасы. Башка чыгу, балаларның мљстәкыйль тормыш коруы табигый хәл. Әмма, кызганыч ки, бу гадәти процесс Алтын Урдада кискен каршылыклар, кан коюлы клњрәш рәвешендә бара. Нәкъ шушы елларда иҗат ителгән мәшһүр «Идегәй» дастаны бик гыйбрәтле юллар белән тљгәлләнә:

Идел йортны дау алды,
Яу љстенә яу килде.
Идегәй әйткән клњн килде,
Чыңгызның куйган хан тагы (тавы.— *Х.М.*)
Кан тагы булып әверелде;
Хан сарае камалды.
Кырым, Казан, Аждаркан (Әстерхан.— *Х.М.*)
Башлы-башлы ил булды,—
Алтын Урда таралды[3].

«Идегәй» — гадәти дастан гына түгел, ә Алтын Урданың җимерелү сәбәпләрен, фаҗигале елъязмасын гәүдәләндергән бљек мәрсия, моң-зар тулы сыктау да ул. Чит патшалар клњче белән үз иленә каршы клњрәшкән кеше рәхәт күрми: ул үзенә дә, халкына да күп зыян китерә. Идегәй дә нәкъ әнә шундый язмышка дучар була.

Дастанда Туктамышны хурлау, тљп каһарманны мактау љстенлек итә. Әмма бу жанр таләбе белән генә шулай эшләнгән. Чынлыкта исә хәл катлаулырак. Алтын Урданың законлы ханы Туктамыш белән клњрәшкә Идегәйне нинди эчке клњч хәрәкәтләндерә соң? Ил язмышы, халык язмышымы? Юк, иң беренче чиратта шәхси үч алу, шәхси мәнфәгать! Күңелендәге шушы иблиси коткы аны иҗтимагый яктан әхлаксыз юлга этәрә: Аксак Тимер гаскәре белән ул Идел-йортка, Туктамышка каршы клњрәш сылтавы белән, исәпсез-хисапсыз бәла-казалар китерә. Бу хакта әсәрдә Бодайби авызыннан Идегәйнең үзенә дә «бу җиһанның фетнәсе Аксак Тимер дошманны Сарайга алып китердең», илне, «шәһре Болгарны», «клњлгә-ташка» болгаттың, дигән шелтәле сүзләр әйттерелә.

Туктамыш юк ителгәч, Идегәй Идел-йортның бљтенлеген, куәтен торгызырга омтыла. Әмма аның, гәрчә ул клњчле, батыр булса да, бу изге максатка ирешә алмаячагы клњн кебек ачык. Ни љчен? Чљнки дастанның тљп каһарманы — илдә таркалу процессына үзе үк нигез салучы. Љендә улы Норадын белән уртак тел таба алмаган хљкемдарның Идел-йортта иминлек урнаштыруына да ышаныч аз. Шунысы гыйбрәтле: Алтын Урда ханына каршы клњрәшкән Идегәй ахырда үзе дә Туктамыш хәлендә кала. Шулай итеп, әхлакый эш-гамәлләргә мљнәсәбәттә шәхси язмышлар да кабатлана.

Алтын Урданың таркалуында һәм татар мәмләкәтләре корылуда, гомумән, аерым шәхесләрнең, бигрәк тә Чыңгыз нәселеннән булган хљкемдарларның роле гаять зур була. Мәсәлән, туганы Кече Мљхәммәд тарафыннан 1438 елда Сарай тәхетеннән куылган Олуг Мљхәммәд 1440 еллар башында Казан ханлыгына нигез сала[4], Касыйм дәүләтенең оешуы да (якынча 1452 елда) аның улы — Касыйм эшчәнлеге белән бәйле.

Тарих китапларында татар ханлыклары арасындагы үзара каршылыклар, сугышлар хакында күп языла. Чыннан да, бу хәл булган. Бердәмлек җитмәү, ызгыш-талаш, кыен вакытларда бер-берсенә тиешле ярдәм итмәү аларның берәм-берәм юкка чыгуына да китерә. Мәсәлән, XVI гасырның урталары — татар мәмләкәтләренең иң киеренке, авыр еллары. Шушы вакытта, ягъни 1549 елда, Кырым ханы, килеп, Әстерхан патшасы Ямгырчыны үтерә[5]. Татар хљкемдарлары арасында каршылыклар тудыруга, аларны бер-берсенә каршы котыртуга сатып алу, бүләкләр бирү, ялганлау, куркыту һәм башка шундый чаралар ярдәмендә Мәскәү хакимияте дә үзеннән зур љлеш кертә. Урыс патшалары ярдәме белән Касыймда һәм Казанда берничә мәртәбә хан булып торган Шаһгали мисалы үзе генә дә күп нәрсә хакында сљйли.

Әлбәттә, татар ханлыклары арасында гел каршылыклар гына булып тормаган. Алар үзара сәүдә итешеп, рухи байлыкларын уртаклашып, бер-берсенә кызлар бирешеп, кода-кодагый булып, ханнар алмашып та яшәгәннәр. Бу чорда бер тљбәктәге татарларның икенче җирләргә күпләп күчеп утырулары да та-

рихтан мәгълүм. XV йөздә, мәсәлән, Дон һәм Идел тамакларыннан, Азак шәһәреннән Урта Иделгә шактый гына татарлар килеп урнаша. Шушы ук гасырда Литвада һәм Польшада татарлар саны 100 меңнән артып китә.

Ислам диненең, язма һәм сөйләмә телнең, мәдәниятнең уртаклыгы, этник якынлык яисә тәңгәллек, Алтын Урда тарихының нигез булып торуы — Казан, Әстерхан, Кырым, Касыйм, Себер, Олы Урда ханлыкларындагы һәм Нугай Урдасы... татарларны үзара якынайтучы, берләштерүче төп факторлар.

Татар мәмләкәтләре, гәрчә Алтын Урда чорындагы кебек булмаса да, күп кенә илләр һәм халыклар белән төрле бәйләнешләрдә торалар. Мәсәлән, Әстерхан, Казан, Кафа, Сарайчык Евразиянең зур сәүдә үзәкләре булган. 1435 — 1439 елларда Кырымда яшәп алган бер испанияле Кафа, Солхат базарларының гаять зурлыгы, аларда Кытай, Һиндстан, Гыйрак һәм кайбер башка илләрнең товарлары сатылуы хакында сокланып яза, хәтта Солхатта Мисыр солтанының махсус вәкиллеге булуын да искәртә[6].

Күп кенә урыс тарихчылары Мәскәү белән татар мәмләкәтләре мөнәсәбәтләрен, гел каралтып, тоташ сугышлар рәвешендә генә күрсәтергә яраталар. (Шунысы гаҗәп: сугыш чыгуда гел татарлар гаепле итеп күрсәтелә. Әйтерсең урыс патшалары, кенәзләре — сөттән ак, судан пакь затлар.) Әмма татарлар белән урыслар арасында тыгыз аралашу, дәвамлы сәүдә мөнәсәбәтләре дә яшәп килгән. Бу хакта күп кенә тарихи факт-мәгълүматлар бар.

Татар ханлыкларында мәгариф вә мәдәният тә билгеле бер үсеш ала. Халыкның күпчелеге ислам динен тота. Шуңа мөнәсәбәттә күп кенә шәһәр-авылларда мәчетләрнең булуы мәгълүм. Алар янында исә мәктәп-мәдрәсәләр эшләгән. Касыйм шәһәрендә, мәсәлән, XV йөзнең урталарында ук инде зур мәчет төзелә. Галимнәр Казан кремле (кальгасы) эчендә сигез манаралы Җәмигъ мәчет, аның янында зур китапханә булуын искәртәләр.

Сәхибгәрәй ханның Казан хөкемдары булганда ук белем-мәгърифәтне яратуы билгеле. Кырым тәхетенә утыргач, ул мәдәни эшчәнлеген тагын да көчәйтә. Бу хакта Ш.Мәрҗани китабында мондый өзек китерелә. «Бу кеше (ягъни Сәхибгәрәй.— *Х.М.*),— диелә анда, — Бакчасарайда хан сарае янындагы Җәмигъ шәрифне (олуг мәчетне.— *Х.М.*) бина кылудан тыш, 170 урында зур һәм кечкенә мәчетләр, мәдрәсәләр бина кылдырып, дөньяда исемен яхшылык белән калдырган»[7]. Әстерхан каласы да үзенең уку йортлары белән дан тоткан, аларда төрле төрки төбәкләрдән килгән шәкертләрнең укуы мәгълүм. Мөдәррисләр арасында, татар укытучылары белән беррәттән, Мисыр, Һиндстан, Урта Азия, Иран, Госманлы укымышлылары да була.

Алтын Урдадагы кебек татар мәмләкәтләрендә дә гарәп-фарсы телләрен, Шәрекъ әдипләренең китапларын өйрәнү киң тарала. Мәктәп-мәдрәсәләрдә, дин сабакларыннан тыш, математика, медицина, логика, тарих кебек дөньяви фәннәр дә укытылган.

## II

Без моңа кадәр Казан ханлыгы чоры мәдәниятен күз алдына китерү һәм билгеле бер дәрәҗәдә аңлау өчен зарури булган тарихи алшартлар һәм аерым факторлар хакында сүз алып бардык. Татар ханлыкларындагы мәдәниятне билгеләүче иң төп фактор, әлбәттә, Алтын Урда. Ул — Казан мәмләкәте чоры татар тормышының рухи культурасының нигезе.

Борынгы һәм Урта гасыр, гомумән, элеккеге чор рухи мирасы хакында сүз барганда, «кызганыч ки» яисә «кызганычка каршы» тәгъбирләрен еш кулланырга туры килә. Бу аеруча татар мәмләкәтләре чоры мәдәниятенә хас. Чөнки бу дәвер рухи истәлекләренең күбесе юкка чыккан. Бу хәлгә, әлбәттә, татар үзе дә гаепледер. Әмма өлешчә генә. Чөнки биредә төп сәбәп — объектив шартларда. Илбасарлар татарны һәм физик, һәм рухи яктан юкка чыгаруны максат итеп куялар һәм гасырлар буена барган рәхимсез көрәштә шактый гына уңышларга да ирешәләр. Шуның нәтиҗәсендә заманында дөньяны шаулатып яшәгән татар халкының саны хәзер дистә миллионга да җитми, алары да бөтен дөньяга сибелгән, яртылашы телен, гореф-гадәтен җуйган яисә югалту, этник бөтенлек буларак тәмам юкка чыгу алдында тора. Хәзерге Татарстан ул элеккеге татар җирләренең бик кечкенә, бармак башы кадәрге өлеше генә. Әмма анда да әле татар һаман үзе хуҗа түгел, аның теле дә хәтта Казанда да юньләп яңгырамый… Кыскасы, татар язма истәлекләренең зур өлеше ханлыклар бетерелү чорында һәм аннан соңгы авыр, караңгы елларда яндырыла, юкка чыга[8]. Кайберләре качып, күчеп киткән кешеләр аркылы чит мәмләкәтләргә, аеруча Төркиягә, Мисырга, Урта Азиягә, Иранга, Һиндстанга һәм өлешчә Көнбатыш Европа илләренә барып эләгә. Андый ядкәрләрне ачыклау, өйрәнү һәм халыкка кире кайтару хәзерге фән алдындагы мөһим бурычларның берсе булып тора.

Шунысын да искәртик: моңа кадәр без, XV — XVI йөзләрдәге татар тарихын, мәдәниятен өйрәнгәндә, нигездә, Казан ханлыгы белән чикләндек. Татарлар яшәгән башка төбәкләргә, мәмләкәтләргә юньләп игътибар да ителмәде. Әйткәнебезчә, алар бер-берсе белән тыгыз аралашып яшәгәннәр. Мәсәлән, Кырым

ханлыгына мънәсәбәтле чыганакларда Идел — Урал буе татарларына кагылышлы факт-мәгълүматлар да күп очрый. Шуңа күрә Алтын Урданың һәм аның җирлегендә барлыкка килгән татар мәмләкәтләренең тарихын, мәдәниятен үзара тыгыз бәйләнештә, бер система рәвешендә карау да көн тәртибендәге җитди мәсьәләләрдән хисаплана. Әмма, кызганыч ки, безнең кул астында хәзерге Әстерхан, Олы Урда, Кырым, Себер, Нугай ханлыкларының тарихына, мәдәниятләренә мънәсәбәтле материаллар бик аз. Булганнарының да шактый өлеше урыс елъязмаларының һәм тарихчыларының тупламында һәм бәяләвендә килеп җиткән. Башка халыкларны кыруны, дәүләтчелеген бетереп, коллыкка төшерүне урысның «бөек рух ирке» («великий дух свободы»), бары «халык колонизациясе» («народная колонизация», «бескровное завоевание», «итогом подвигов колонизации») дип атаган һәм юлбасар Ермакка каршы үз бәйсезлеген яклап көрәшкән Себер ханын «килмешәк һәм басып алучы» («пришелец и завоеватель») дип бәяләгән Р.Г.Скрынников[9] һәм язъзарлаган башка бөек мәмләкәтчел китап авторларыннан татар тарихы хакында чын һәм гадел мәгълүматлар көтү[10], әлбәттә, файдасыз эш. Шуңа күрә без, гәрчә бик теләмәсәк тә, XV — XVI йъзләр татар мәдәниятен хәзергә Урта Идел Казан ханлыгы белән генә чикләбрәк карарга мәҗбүр булабыз. Анда да әле бушлыклар, томанлы урыннар шактый күп. Дөрес, соңгы елларда И.В.Нәүрузханның «Сөембикә» романында, Р.Батулланың «Сөембикә кыйссасы»нда, Ф.Латыйфиның «Хыянәт» повестенда, М.Хәбибуллинның «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» әсәрендә XVI гасырның беренче яртысындагы татар хәятын, аеруча Казан тормышын гәүдәләндерүдә уңышлы гына адымнар ясалды. Аларның авторлары күп кенә тарихи фактларны һәм мәгълүматларны теге яки бу дәрәҗәдә файдаланганнар. Әмма бу төр китапларның фәнни хезмәт түгел, ә әдәби әсәр булуын, аларда авторларның хыял-фантазиясе гаять зур роль уйнавын һич тә онытырга ярамый. Галим-тикшеренүче өчен исә иң мөһиме — чыганак, бар булган факт-мәгълүмат. Ул шуларга таянып кына фикерли һәм кирәк чакта гөман (фараз) кыла ала.

### III

Халык телендә бик борынгы, кадими күренешләргә карата «хан заманыннан калган» дип әйтү еш ишетелә. Ныклабрак уйлап караганда, безгә ул чордан килеп җиткән мирасның иң зурысы, иң кадерлесе — ул безнең газиз татар телебез. Аның төп лексик фонды, грамматикасы, фонетикасы шул «хан заманнарында» ук тәмам оешып, камилләшеп җиткән. Моны шул чордан сакланып калган язма истәлекләрнең тел-стиле дә ачык күрсәтеп тора.

Тел — ул халыкның шифрга салынган хәтере. Әгәр дә ачкычын табып, аны укый белсәң, тарихи тормышның, рухи дөньяның күп якларын ачыкларга була[11]. Мөхәммәдьяр поэмасындагы Заһид хикәятендә бер хөкемдар «йөзигә кара сөртеп үлтерең» дигән әмер бирә. Баксаң, М.Гафури повестенда сурәтләнгән биткә кара сөртү җәзасы халыкта күптәннән кулланыла икән. «Төхфәи мәрдан» әсәрендә «Аның имен (дәвасын.— *Х.М.*) һич утачы белмәгәй» дигән юл бар. «Утачы» атамасының тамырын «ут» (үлән) сүзе тәшкил итә (хәзерге телебездәге «утлавык», «утлау», «утау» кебек сүзләр нәкъ шуның белән бәйле). «Утачы» исә «үлән белән дәвалаучы», «табиб» мәгънәсен белдерә. Элеккеге язма истәлекләрдә, аеруча эпитафик ядкәрләрдә «дарелбәка» (мәңгелек йорт, ягъни теге дөнья), «дарелфәна» (вакытлы йорт, ягъни бу дөнья), «рихләт кылды» (күчеп китте, үлде), «җаны кош булып очты» гыйбарәләре күзгә еш ташлана. Бу төр тәгъбирләр исә шул дәвер кешеләренең мифологик ышанулары, дөнья, яшәеш хакындагы күзаллаулары белән тыгыз бәйләнешле. Телдә генә түгел, татар халык авыз иҗатының бүгенге мирасында да Казан ханлыгы чоры белән бәйләнешле истәлекләр шактый. Аларның бер өлеше теге яки бу дәрәҗәдә үзгәргән, икенчеләре чагыштырмача бөтен, мөстәкыйль хәлендә сакланып калган[12]. Алар арасында Иске һәм Яңа Казанның салынуы, Кабан күле, Елан тавы, Сөембикә, Җик Мәргән хакында риваятьләр, әкиятләр бар. XV — XVI йъзләргә мънәсәбәтле фольклор истәлекләренең иң күренеклесе,— әлбәттә, «Идегәй» дастаны. Ул, бер яктан, Алтын Урда җирлегенә, икенче яктан, фольклор һәм язма әдәби казанышларга нигезләнеп туган сирәк очрый торган (уникаль) күренеш. Анда халыкның күп гасырлык шигъри фикерләве, кеше, яшәеш хакындагы уйланулары, хикмәтле сүз әйтү осталыгы фокустагы кебек бергә тупланып бирелгән. Бу дастан үзе генә дә элеккеге сүз сәнгатебезнең нинди югары дәрәҗәдә торуын күрсәтүче бер дәлил.

Казан ханлыгы чорында язылган, укылган, шул дәвердән безгә килеп җиткән язма истәлекләр үзләренең табигатьләре белән гаять төрле. Алар арасында без төркичә, гарәпчә, фарсыча текстларны да, әдәби әсәрләрне дә, гыйльми, дини китапларны да, каберташ язмаларын һәм ярлыкларны да, тәрҗемә һәм оригиналь ядкәрләрне дә очратабыз. Хәзер шуларның кайберләренә кыскача гына тукталып үтик. Элеккеге төрки-татар язма истәлекләренең күпчелеге («Кыйссаи Йосыф», «Кыйссасел-әнбия», «Нәһҗелфәрадис», «Җөмҗөмә солтан», «Кисекбаш» һ.б.) Казан ханлыгы чорында да укылуларын дәвам итәләр. Мәсәлән, 1521 — 1524 елларда Казан, 1532 — 1550 елларда Кырым тәхетендә утырган Сәхибгәрәй ханның

шәхси китапханәсендә Хисам Кятиб поэмасының да булуы мәгълүм. Төрек галиме Ф.Күпрелзадә фикеренчә, «Җөмҗөмә солтан» Сәхибгәрәй хан әмере белән 1549 елда госманлы теленә дә тәрҗемә кылына.

Йосыф Баласагунлы (XI йөз), Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани (XII гасыр), Йуныс Эмре (1250 — 1320), Гашыйк Паша (1271 — 1332), Лотфый (1366 — 1465) һәм кайбер башка төрки әдипләренең әсәрләре дә татар мәмләкәтләрендә таралыш таба. Лотфый, мәсәлән, үзе дә Сарай, Казан калаларында була. Татар укучылары тарафыннан аның аеруча «Гөл вә Нәүрүз» дастаны (1411) яратып укыла. Төрки әдипләренең олуг остазы Нәваи да (1441 — 1501) — үз чорында ук татар укымышлыларына якын исем. Шагыйрь әсәрләренең XVI йөздә төзелгән бер кулъязмасы Казанга мөнәсәбәтле. Госманлы әдибе Язычуглының (1451 елда үлә) «Мөхәммәдия»се — Октябрь инкыйлабына кадәрге татар укучыларының иң яраткан китапларыннан берсе. Бу поэма да XV — XVI йөзләрдә үк Идел—Урал буйларына кергән булырга мөмкин.

Алтын Урда кебек үк татар мәмләкәтләре дә — зур мөселман дөньясының мөһим төбәкләре. Шуңа күрә гарәп һәм фарсы телләрендәге мәдәни һәм гыйльми ядкәрләрнең оригиналда, төрле тәрҗемәләрдә һәм шәрехләрдә татар укучыларына ирешүе табигый хәл. Коръәннең һәр мөселманга, шул исәптән татарларга да мәгълүм булуы бәхәссез хакыйкать. Аның 1507 елда Казанда төзелгән тәфсире хәзер дә Татарстан дәүләт музеенда саклана. Шәрекънең Ибне Сина, Фирдәүси, Газали, Низами, Гаттар, Сәгъди, Җәләледдин Румый кебек мәшһүр классиклары да — татар мәмләкәтләрендә билгеле затлар. «Кәлилә вә Димнә», «Тутыйнамә», «1001 кичә» җыентыклары оригиналда яисә тәрҗемәләрдә безнең әби-бабаларыбыз тарафыннан яратып укыла һәм тыңлана, алардагы аерым сюжетлар һәм мотивлар татар авторларының әсәрләрендә дә файдаланыла.

Гарәп-фарсы галиме Зәкәрия Казвининең (1203 — 1283) «Гаҗаибел мәхлукат вә гараибел мәүҗүдат» («Искитмәле җан ияләре һәм яшәешнең могҗизалары») исемле атаклы китабы бар. Анда мавыктыргыч һәм үтемле формада табигать, галәм, дөнья турында күптөрле мәгълүматлар бирелә. Гарәп телендәге бу хезмәт Казан мәмләкәтендә укылган икән. Академик И.Крачковский язуынча, 1549 елда Казан ханлыгыннан Кырымга илчелек җибәрелә. Андагы кешеләр юлда мәскәүлеләр тарафыннан әсир ителә. Шушы вакытта Казан илчелегеннән алынган Казвини китабы Мәскәү патшасының казнасына тапшырыла[13]. Шунысы мөһим: «Гаҗаибел мәхлукат...» татарларда XVI йөздән соң да укыла. XIX гасырда аның Казанда нәшер ителүе дә мәгълүм.

XV — XVI йөзләргә мөнәсәбәтле язма истәлекләрнең бер өлешен ярлыклар тәшкил итә. М.Госманов тикшеренүләре күрсәтүенчә, аларның саны 60 ка якыная[14]. Табылган ярлыкларның икесе Казан (Ибраһим, Сәхибгәрәй), 56 сы Кырым (Хаҗигәрәй, Миңлегәрәй, Мөхәммәдгәрәй, Сәгадәтгәрәй, Сәхибгәрәй, Дәүләтгәрәй һ.б.) ханнарына карый. Татар телендә язылган бу ядкәрләрнең күпчелеге оригиналда, ә бер өлеше төрле күчермәләрдә һәм тәрҗемәләрдә килеп җиткән.

Хан ярлыклары — татар тарихын, мәмләкәтләрен өйрәнүдә, аларның үзара һәм башка илләр, халыклар белән элемтәләрен ачыклауда гаять мөһим чыганак. Мәсәлән, Сәхибгәрәй хан ярлыгында (1523)[15] без Казан дәүләтендәге социаль һәм юридик атамалар, кеше исемнәре белән очрашабыз, аның ярдәмендә хакимият һәм рәгыять (халык) мөнәсәбәтләре хакында билгеле бер күзаллау тудырабыз. Кызганыч ки, әле бу ядкәрләр, тарихчылар һәм аеруча телчеләр тарафыннан тиешенчә өйрәнелеп, гыйльми әйләнешкә кертелмәгәннәр.

1928 — 1939 елларда нәшер итеп киленгән «Яңа милли юл» журналының[16] 1937 елгы 3 (108) нче санында «Олуг Мөхәммәднең солтан Морадка язган мәктүбе» дигән кызыклы гына бер мәкаләсе бар (15 — 17 б.). Анда Истанбул университеты доценты, милләттәшебез Акъдәс Нигъмәт Куратның[17] Төркия архивыннан «Олуг Мөхәммәд ханның госманлы падишаһларыннан Икенче Морадка язган бер ярлыгын табып чыгаруы» һәм бу хакта галимнәр алдында доклад ясавы хакында хәбәр ителә. Бу мәктүб 931/1427 елда язылган. «Ярлыкның биш йиренә Олуг Мөхәммәднең исемен эченә алган мөһер басылган». Бу язмада Алтын Урда ханы «атасы Туктамыш хан (кайбер язма чыганаклар аны Олуг Мөхәммәднең бабасы дип күрсәтә.— *Х.М.*) заманында да госманлы дәүләте берлә илче, сәлам вә бүләкләр алышу кеби мөнәсәбәттә булган булуын», шуны дәвам иттерергә теләге барлыгын бәян итә. Күрәсез, бу документ XV йөз татар тарихы белән турыдан-туры бәйле һәм аны безнең матбугатта бастырып чыгару мөһим эш булыр иде.

Шунысы әһәмиятле: Алтын Урда, Кырым һәм Казан ханнарының ярлыклары тел ягыннан бердәй яисә үзара бик якын. Бу үзе үк XV — XVI йөзләрдәге татар мәмләкәтләренең этник һәм мәдәни якынлыгын, аларда бер үк язма тел — Алтын Урда чорындагы төрки-татар теленең дәвам ителешен күрсәтә.

Вафат булган кешеләрнең кабере өстенә язулы ташлар кую татар мәмләкәтләре дәверендә дә дәвам итә. Бизәкләре, язу рәвешләре һәм эчтәлекләре белән алар сәнгати һәм тарихи яктан игътибарга лаек. Сакланып калган кайбер каберташ язмаларында шигъри юллар да бар. Шуларның берсендә (1552 елда

куелган бу таш Вятка тљбәгенең Нократ авылында сакланган) антитеза ярдәмендә яшәешнең куаныч икәнлеге, үлемнең «љметләрне љзеп китүче» аянычлы, рәхимсез хәл булуы рәсемләнә:

Үлем куанычысы йитте,
Безем куанычымыз китте;
Мәгәр шоңкар булып очты,—
Табылмас эстәгән (теләгән.— *Х.М.*) берлә...[18]

Биредә үлем җанның кош (бу очракта шоңкар — лачын, ау кошы) булып очып китүе рәвешендә күзаллана. Мифологик ышануларга бәйләнешле бу сурәт борынгы тљрки язма истәлекләреннән алып Кол Гали, Котб, Сәйф Сараи, Мљхәммәдъяр һәм кайбер башка авторлар аша Тукайга килеп җитә.

**IV**

XVI йљз шагыйре Мљхәммәдъяр, Казан каласын күздә тотып, болай яза:

Бер гаҗип бу кем шәһренең эче тулуг:
Шагыйрь улмышлар барча — кечек һәм олуг.

Әмма, кызганыч ки (янә бу гыйбарәне кулланырга мәҗбүрбез), Казан дәүләтенең һәм башка татар мәмләкәтләренең бик аз санлы әдипләре генә безгә мәгълүм. Аларның да иҗат мираслары, нигездә, љзек-кљтек кенә сакланган.

Иң әүвәл эчне пошырган бер мәсьәләгә тукталып китик. Ул да булса — безнең гадәттән тыш «бәйнәлмиләлче» булуыбыз. Профессор И.Таһиров үзенең бер гаять кызыклы мәкаләсендә болай дигән иде: «Татарның тарихы, аны љйрәнү чыганаклары халыкның үзе кебек үк бљтен дљньяга чәчелгән, сибелгән. Шунлыктан аның яхшы күренгән, үзләренә хуш килгән урыннарын башка халыклар, үзләштереп, үз мираслары иткәннәр. Мәсәлән, Идел буенда туып үскән, соңрак Мисырда солтан булган Бәйбарс бүген казах итеп күрсәтелә. Бу җәһәттән милләттәшебез Булат Мансуров та моңа љлеш кертте. Ул, «Казахфильм»да Бәйбарска багышланган фильм эшләп, шушы тарихи шәхесне дљньяга казах итеп танытты». (Алтын Урда: миф һәм чынбарлык // Шәһри Казан.— 1993.— 15 май.) Безнең күренекле бер әдибебез дә моннан дистә еллар элек, башкортлар алдында артык юмартланып, М.Гафуриның кайсы милләт язучысы булуы мљһим түгел, дип язып чыккан иде. Шушындый артык гадилегебез, киң күңеллелегебез, чын «интернационалист» булуыбыз аркасында инде без күпме талантларыбыздан, рухи байлыктан колак каккан?! Моны Ходай Тәгалә бер үзе генә беләдер.

Үзебезне болгар белән чикләргә тырышу, татар тарихын хәзерге Татарстан җире белән генә тәңгәл кую, Алтын Урдага һәм башка татар мәмләкәтләренә тискәре торуыбыз аркасында халкыбызның урта гасырлардагы күпме рухи хәзинәсе укучылар игътибарыннан читтә кала килде! Бу кимчелекне бетерүдә «Татар поэзиясе антологиясе»н тљзүчеләр җитди генә адымнар ясаганнар. Мәсәлән, аңа XV — XVI йљзләргә мљнәсәбәтле Хәсән Кайгы, Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз кебек авторларны кертеп бик дљрес эшләнгән. Моңа кадәр фәндә бу шагыйрьләр, нигездә, казах әдәбияты вәкилләре рәвешендә генә каралып килде[19]. Ә бит алар чынлыкта татар җирлеге, татар кавеме, татар мәмләкәтләре белән бәйләнешле. Казтуган — чыгышы белән Әстерхан татары. Аның XV йљздә Идел тамагындагы хәзерге Кызылъяр тљбәгендә аксљяк гаиләсендә туып үсүе мәгълүм. Ул батырлыгы, чичәнлеге белән дан тота. Казтуган Сљенеч угылын еш кына «Казтуган батыр», «Казтуган җырау» дип тә йљртәләр.

XV йљздә яшәгән Хәсән Кайгының (Хәсән Сабит угылының) да тумышы Идел-йорт белән бәйләнешле. Ул Олуг Мљхәммәд даирәсендә әүвәл Сарайда, аннан Казан ханлыгында яши. Хљрмәтле, дәрәҗәле кешеләрнең берсе була. Гомеренең ахырында Нугай Урдасына күчеп китә. Дусмәмбәт XV гасырның соңгы чирегендә татарларның билгеле шәһәре — Азакта (хәзерге Азов) туып үсә. Хәрби. XVI йљзнең 20 нче елларында сугышта алган ярасыннан үлеп китә. Чалгиз җырау (XV йљзнең соңгы чирege — 1560 еллар) — Сљембикәнең туганнан туганы. Яшәгән, иҗат иткән тљбәге — Идел-Җаек арасы, Идел-йорт.

Бу шагыйрьләрнең әсәрләре элек-электән үк татарларда укылган, Октябрь инкыйлабына кадәр Оренбург, Казан нәшриятларында басылып та чыккан. Димәк, бу әдипләрне без хаклы рәвештә XV — XVI йљз татар әдәбияты вәкилләре дип карый алабыз. Әмма шуның белән бергә без аларның казахлар арасында да яратып тыңлануын, укылуын да истән чыгармаска тиешбез. Урта гасыр Идел-Урал буе әдәби истәлекләренең, шул исәптән Хәсән Кайгы, Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз әсәрләренең дә, нигездә, татар телендә иҗат ителүе бәхәссез хакыйкать. Ә инде аларның кулланылуы, таралу вакытында тел ягыннан љлешчә казахлаштырылуы табигый һәм чагыштырмача соңрак күренеш. Үкенечкә каршы, «Татар поэзиясе антологиясе»нә текстлар бу үзенчәлекне тиешенчә исәпкә алмыйча гына урнаштырылганнар.

Ђлешчә «казахлашып» киткән бу дүрт шагыйрь иҗатына нинди сыйфатлар хас соң? 1. Аксак Тимер тарафыннан Алтын Урда шәһәрләре җимерелгәч, Идел-Җаек тђбәгендә утрак тормыш шактый дәрәҗәдә зәгыйфьләнеп китә. Шуның нәтиҗәсе буларак язма һәм авыз иҗатын синтезлау рәвешендәге сәнгати башлангыч кђчәя. Чичәнлеккә тартым бу күренеш Хәсән Кайгы, Казтуган, Дусмәмбәт, Чалгиз әсәрләрендә дә күзәтелә. Шунысы мђһим: хикмәтле сүз әйтүгә, бәдиһә — импровизациягә корылган бу традиция Акмулла һәм Дәрдемәнд иҗатларында аеруча нык дәвам иттерелде. 2. Һәр дүрт шагыйрьнең әсәрләре дә дастан жанры, аеруча «Идегәй» белән якын. Ул тел-стильдә дә, шигъри үлчәм, строфа, рифма тђзелешендә дә, ђлешчә эчтәлектә дә күзгә ташлана. Хәтта охшаш юллар да очрап куя. Мәсәлән, Казтуганның:

Атамыз безнең бу Сђенеч
Кияү булып барган йорт.
Анамыз безнең Бүзтуган
Киленчәк булып тђшкән йорт,—

дигән юллары «Идегәй»нең хәзерге вакытта җыр итеп җырлана торган ђзеген искә тђшерә. 3. Дүрт әдипнең дә шигырьләрендә туган җиргә, аеруча Идел-йортка, Идел-Җаекка мәхәббәт, дан җырлана. Дусмәмбәт ђчен туган шәһәре Азак Истанбулдан ким түгел («Азаулының Истанбулдан нисе ким?»). Туган җиренә сокланып, Казтуган: «Хәйран минем Иделем!» — ди. 4. Хәсән Кайгы һәм аның чордашлары ђчен дђньявилык, хђрлек, горурлык, тулы канлы тормышны, яшәешне олылау хас. Авторлар шигъри чаралар ярдәмендә үз укучыларына һәм тыңлаучыларына гуманистик сабак, әхлакый үгет-нәсихәт бирәләр: «Карендәшең яманлап, үзеңә туган табылмас», «Киңәшсез сүз башлама», «Исәнең дә, терең дә — бер булыгыз барыгыз» (Хәсән Кайгы); «Хан улыннан артык иде минем нәсәбем», «Ару сђйдем — үкенмәм, бүген соң да үкенмәм» (Казтуган) һ.б. 5. Һәр дүрт әдипнең әсәрләрендә дә табигатькә якынлык, аңа янәшә яисә капма-каршы кую юлы белән кешенең рухи халәтен, әхлакый, иҗтимагый күренешләрне тасвирлау хас. Менә Хәсән Кайгының бер шигыре:

Күлдә йђргән кыңгыр каз,
Кырда йђргән дуадак,
Авылдагы яманнар
Күчеп-кунып күрмәгән (йђрмәгән.— *Х.М.*).

Кыр кадерен ни белсен?!
Су кадерен ни белсен?!
Ир кадерен ни белсен?!
Җир кадерен ни белсен?!

Күчсә, куна белмәгән,
Акылына күнмәгән, —
Кунса, күчә белмәгән,
Йорт кадерен ни белсен!

Казан ханлыгы чорының исеме билгеле булган шагыйрьләреннән берсе — Мђхәммәд Әмин. Фәндә аны 1487 — 1496, 1502 — 1518 елларда Казан ханы булып торган Мђхәммәд Әмин белән бер үк зат дип хисаплыйлар.

Бу хђкемдарның фәнгә, әдәбиятка, сәнгатькә хәерхаһ булуы мәгълүм. Атаклы шагыйрь, дәүләт эшлеклесе, галим Бабур (1483 — 1530) язуынча, Мђхәммәд Әмин үтенече белән Шәйбани хан үзенең берничә җырчы-музыкантын һәм рәссамын Казанга җибәрә. Бүгенге кђнгә кадәр килеп җиткән бер савытка татарча һәм фарсыча шигъри юллар теркәлгән. Татарстан дәүләт музеенда сакланучы бу матур, бизәкле комганны да Мђхәммәд Әминнең бакырчы остасы — Насыйр ясаган. Бу хан вафат булгач, аның тђрбәсендә Мђхәммәдъярның сакчы булып торуы очраклы хәл булмаска тиеш. Кыскасы, Казан хђкемдарының әдәби иҗат белән дә шђгыльләнүе һич тә гайре табигый күренеш түгел.

Мђхәммәдзариф Хђсәенов үзенең «Тәварихе Болгария» исемле китабында (Казан, 1883.— 60 б.) Мђхәммәд Әминнең 12 юллык «Гыйкаб» («Үч») исемле шигырен китерә. Бу парчада шагыйрь, үз элгәреләре Сәйф Сараи, Әхмәд Үргәнчи, Баззази традицияләрен дәвам итеп, Аксак Тимернең шәхесен («Үзе — аксак, гаклы — ахмак, фетнәдар»), эш-гамәлләрен кискен тәнкыйтьли, аның җиргә, «ислам йортына» «золым», «фетнә» китерүен күрсәтә һәм Алладан бу «залим»га каты җәза бирүен үтенә.

Идел-Җаек буйларындагы татар мәмләкәтләре бетерелгәннән соң туган аерым ядкәрләрдә («Җәмигъ әт-тәварих», «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер һ.б.). Чыңгыз хан һәм Аксак Тимерне идеаллаштыру, әкияти, дастани каһарман рәвешендә гәүдәләндерү дә күзгә ташлана. Бу, күрәсең, Мәскәү хакимиятенең милли-колониаль сәясәтенә тђрки-татарларның элеккеге тарихын, мђстәкыйль дәүләтчелеккә ия булган заманнарын каршы кую максатыннан эшләнгәндер.

XV — XVI йљзләрдә башка әдипләрнең дә булуы билгеле. Мәсәлән, аерым хезмәтләрдә Гарифбәк исемле шагыйрьнең Сљембикә хезмәтендә булуы, Болгар, Казан тарихына кагылышлы әсәр язуы искәртелә. Әмма бу әдипнең китаплары безгә мәгълүм түгел. Ш.Абилов фикеренчә, XVI йљзнең урталарында Казанда Мљхәммәдшәриф исемле язучы да яшәгән. Аның тљрек солтаннарыннан берсенең үтенече буенча язган зур күләмле әдәби әсәре хәзерге вакытта Истанбулда саклана икән. Татар галиме бу мәгълүматларны А.Курат сүзләренә таянып әйтә[20]. (Бу мљһим мәсьәләне ачыкларга иде!) Кайберәүләр XVI йљздә иҗат иткән Максуди һәм Касыйми дигән тљрки шагыйрьләрне дә Идел буена нисбәт итәләр. Максудиның шигъри хикәятләрне туплаган җыентыгы (ул 1515 елда тәмамланган) XIX гасырда Казанда берничә мәртәбә нәшер дә ителә[21].

## V

Казан ханлыгы дәверенә мљнәсәбәтле әдипләрнең иң күренеклеләреннән берсе — Љмми Кәмал. Аның шигырьләре татарлар арасында гаять нык таралган. Миңа, мәсәлән, университет студентлары белән Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Чиләбе, Оренбург, Ульяновск, Горький, Пермь тљбәкләренә оештырылган дистәдән артык фольклор, археографик экспедицияләрдә катнашырга туры килде. Бу сәфәрләрнең һәрберсендә диярлек без Љмми Кәмал шигырьләренә тап була идек. Күпсанлы кулъязмаларыннан тыш, шагыйрь әсәрләре Казанда берничә мәртәбә аерым китап рәвешендә дә нәшер ителгән (1884, 1898, 1899, 1906 һ.б.). Басылган җыентыклар, нигездә, бер-берсен кабатлыйлар. Без аларның 1897 елгы басмасына таянып фикер йљртербез[22]. Бу китап «Габдерәхман бине Госман әл-Каргалый» исемле зат тарафыннан тљзелгән. Җыентыкның ахырын, ягъни 107 — 112 битләрен, XIX йљз татар шагыйре Әбелмәних Каргалыйның 12 шигыре алып тора. (Барлыгы 125 бит.)

Љмми Кәмал — шагыйрьнең кушаматы, исеме исә Исмәгыйль. Бу хакта әдип үзе дә искәртә:

> Колларың кәмтәредер (кечкенәседер.— *Х.М.*) Исмәгыйль.
> Нә вар Љмми Кәмал исә ләкабе.

Шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә мљнәсәбәтле мәгълүматлар юньләп сакланмаган. Берәүләр аны Идел буена, икенчеләре исә Кече Азиягә тарта. Чынлыкта исә Љмми Кәмал бу ике тљбәк белән дә бәйләнешле. Ул, үз гомеренең шактый љлешен Идел-Җаек буйларында һәм Кырымда уздырып, аннан Тљркиягә күчеп киткән булса кирәк. Үлеме 1475 елга карый.

Шагыйрьнең бер урында гына яшәмәве аның әсәрләрендә дә чагылган. Ул еш кына мљһаҗирлек (горбәтлек, гариблек) турында яза. Мәсәлән, бер шигырендә ул болай ди: «Гарибәм, горбәтә килдем илемдән».

Љмми Кәмалның татар белән бәйләнешле булуы аның иҗатында да ачык күренә. Беренчедән, шагыйрь, гәрчә сирәк булса да, «татар» атамасын да телгә ала: «татарәм» («мин татар», 15 б.), «йаге татар» («татар гаскәре», «татар мае», «татар дәвасы», 26 б.) һ.б. Икенчедән, әдип әсәрләренең теле XIII — XV йљзләрдәге иске татар язма әдәби теле белән турыдан-туры керешеп китә. Госманлы теленә генә хас элементлар, сүзләр анда чагыштырмача сирәк очрый: шимди (хәзер), чәләби һ.б. Әмма алар да кайвакыт тљрки-татар берәмлекләре белән синоним рәвешендә кулланылалар. Љченчедән, Љмми Кәмал шигырьләре Әхмәд Ясәви, Сљләйман Бакыргани, Кол Гали, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб, Сәйф Сараи иҗатлары аша килә торган әдәби традицияләрнең дәвамы рәвешендә кабул ителә. Дүртенчедән, Љмми Кәмал әсәрләре, башка тљрки тљбәкләрдән үзгә буларак, нәкъ менә татар укучылары арасында элек тә, соңгы дәвердә дә аеруча киң таралыш тапкан. Мәүла Колый, Утыз Имәни, Әбелмәних Каргалый, Шәмседдин Зәки, Дәрдемәнд кебек татар әдипләренә кљчле йогынты ясаган. Бишенчедән, XIV—XV йљзләрдә мљселман, шул исәптән тљрки дљньясындагы галим-әдипләрнең, суфиларның, руханиларның яшәү урыннарын алыштырып торулары киң таралган күренеш. Шуңа күрә Љмми Кәмалның да мљһаҗирлеге гайре табигый күренергә тиеш түгел. Кыскасы, Љмми Кәмал иҗатын татар әдәбияты контекстында карау урынлы һәм зарури күренеш. Әмма, кызганыч ки, бу талантлы шагыйрьнең иҗаты махсус рәвештә бљтенләй диярлек тикшерелгәне юк. Әсәрләре дә хәзерге укучылар игътибарыннан һаман да читтә кала килә.

Љмми Кәмал — үзенең иҗатында гына түгел, ә тормышында да суфичылык тарикате белән бәйләнешле шәхес. Берничә шигырендә ул үзенең шәех-остазларын телгә ала, аларга махсус мәдхия-мәрсияләр дә багышлый. Әдип љчен аеруча Хуҗа Галибәк дигән кеше якын (13 б.), ул аны җиһанның, замананың «котбе», ягъни «үзәге», «акыл иясе» дип атый: «Ул шәйх җиһане котбе заман Хуҗа Галидер» (99 б.). («Котбе заман» сурәте XVIII йљз татар поэзиясендә Мљхәммәдҗанга багышланган мәдхиядә дә кулланыла.) Ике мәрсиясендә шагыйрь янә берничә остазын хљрмәт белән искә ала. Алар арасында 815 (1412), 832 (1429) елларда вафат булган Хәмид Хаҗи Салих һәм Хуҗа Садреддин исемле затлар да бар (16—18

б.). Мәрсияләрдән авторның бу кешеләрне якыннан белүе аңлашыла («хәзрәтем китде», ягъни үлде...). Бу фактлар шагыйрьнең туган елын якынча XIV гасыр азакларына нисбәт итәргә нигез бирәләр.

«Китабе Ључми Кәмал» җыентыгында авторның 140 шигыре урнаштырылган. Аларның гомуми күләме 3255 строфадан гыйбарәт (күпчелеге — икеюллыклар, ягъни бәетләр; берничә шигырь дүртьюллыклар белән язылган). Шигырьләрнең уртача күләме — 23 бәетле. (Иң кечкенәләре 5 әр строфалы, иң зурларында бәетләр саны 100 дән артып китә. Арада 201, 155, 135 строфалы әсәрләр дә очрап куя.) Китаптагы шигырьләрнең күпчелеге форма ягыннан газәл жанрында; рифмалашулары аа ба ва... рәвешендә, Ључми Кәмал әсәрләренең бер љлешен мљнәҗәтләр, мәдхия-мәрсияләр тәшкил итә. Шагыйрь әсәрләренең барысы љчен дә диярлек тәхәллүс куллану хас. Соңгы яисә аннан алдагы строфаларда автор кушаматының телгә алынуы әсәрләргә билгеле бер конкретлык кертә, шәхси тљсмер љсти.

Ључми Кәмалның җыентыктагы әсәрләре, бер-ике сюжетлы күренешне исәпкә алмаганда, барысы да диярлек лирик характерда. Аларда уй-кичерешләр, хис-тойгылар гаять кљчле һәм тирән бирелгән. Авторның лирик каһарманы аллачыл, диндар кеше. Ул бљтен күңелен, бљтен барлыгын үзенең идеалы — олуг Тәңрегә юнәлткән: ул аны сљя, аңа омтыла, ахыр чиктә аның белән кушылырга тели. Моның љчен нәрсә эшләргә кирәк соң? Барыннан да бигрәк дљньяның малына, рәхәт-ләззәтенә, тәхет-таҗына кызыкмаска кирәк. («Дљнья сүмәк — һәр хатаның башыдыр», 92 б.) Чљнки алар бар да вакытлы. Кеше, нәфсе колы булудан туктап, үз күңелен пакьләргә, игелекле гамәлләр генә кылырга, булган гљнаһларыннан арынырга бурычлы. Шагыйрьнең күп кенә шигъри юллары лирик каһарманны битәрләүгә, аны гљнаһ кылуда, бозыклыкта гаепләүгә корылган. Ључми Кәмал иҗаты тулысы белән суфичылык рухында. Ул бу тәгълиматка мљнәсәбәтле тљшенчәләрне һәм символларны гаять мул һәм иркен куллана (тарикать, мәгърифәт, гафләт, мәгъшук, юл, мәнзил, бакый, фани, пәрванә, шәмгъ, бәхер, былбыл, гљл, кафәс, нәфес, шәраб, кәбаб һ.б.). Әмма шунысы мљһим: Ључми Кәмал шушы билгеле атамаларның гаять күптљрле тљсмерләрен, вариантларын, тљшенчәләрен тудыра, аларга чын мәгънәсендә индивидуальлек, шигърилек рухы љсти. Мәсәлән: «Азук юк, юл иясез, вар чук хәрами» (юлбасарлык, 42 б.); «Гафләт илә кичде гомрем аһ-у-аһ. Сачем ак, йљзем кара, эшем гљнаһ» (52 б.); «Тән кафәсдер (читлектер.— *Х.М.*) бәндә җаным, кошы кунакдыр бәнем» (87 б.) һ.б.

Ључми Кәмал иҗаты, гәрчә анда пессимизм, сагыш кљчле булса да, гомумән, гуманизм рухы белән сугарылган. Шагыйрь Алланың берлеге, бљеклеге аша кешеләрнең табигый тигезлеге идеясен үткәрә. Ул үз укучыларын «горрә» (тәкәббер) булмаска, «хәрәмләшмәскә», гайбәт сљйләмәскә, ялганламаска, бар әйбереңне «юклыга» бирергә, бары «тугры юл»дан гына йљрергә чакыра.

Гомумән, Ључми Кәмал иҗаты — Ясәви, Бакыргани, Хисам Кятибләрдән килә торган әдәби традицияләрне дәвам иттерүдә, үстерүдә һәм баетуда мљһим бер буын. Үз чиратында ул үзеннән соңгы татар әдипләренә зур йогынты ясады. Үзенең иҗади рухы белән Ључми Кәмалга якын торучы татар әдипләренең берсе — Кол Шәриф.

## VI

Мљхәммәдъяр һәм Кол Шәриф — XV — XVI йљзләрдәге татар әдәбиятының Казан белән турыдан-туры бәйләнешле әдипләре. Аларның һәр икесе дә XVI гасырның беренче яртысында яшәгәннәр һәм иҗат иткәннәр, Казан мәмләкәтенең мәдәни тормышында кайнаганнар. Бу ике шагыйрьнең үзара аралашуы, бер-берсен яхшы белүе дә мәгълүм. Мљхәммәдъяр һәм Кол Шәриф исемнәре һәм элеккеге, һәм хәзерге укучыларга ярыйсы таныш. Алар иҗат иткән әсәрләрнең кулъязмалары, басма нљсхәләре шактый.

**Кол Шәриф**. Тарихи чыганакларда һәм хезмәтләрдә бу кешенең затлы нәселдән булуы, тәрбиялелеге, укымышлыгы, хљрмәт иясе икәнлеге искәртелә. Казан ханлыгының соңгы елларын күздә тотып, Ш.Мәрҗани болай язды: «Галимнәрдән, хљрмәткә лаек габбасилардан һәм бљек сәетләрдән күпмедер шәхесләр булып, аларның башында нәкыйбел-әшраф дип танылган мелла Шәрифкол исемле бер зат тора. Ул ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирамга һәм зур хљрмәткә лаек була»[23]. Руханилар җитәкчесе, ягъни сәетлек вазифасын үтәүгә Кол Шәриф, әтисе Мансур үлгәч, 1546 елда керешә. Бу — Казан мәмләкәтенең катлаулы, каршылыклы, һәлакәт алды еллары. Кол Шәриф илдә иминлекне торгызырга, Казан белән Мәскәү арасындагы мљнәсәбәтләрне тыныч, сәяси юл белән хәл итәргә омтыла. Әмма Явыз Иван хљкүмәте аның тәкъдимнәрен кире кага һәм Казанга каршы кан коюлы сугыш башлый. Башка чара калмагач, Кол Шәриф тә, бүтән ватандашлары белән берлектә, үз иленең, халкының бәйсезлеген саклап кљрәшкә күтәрелә. Бу хакта янә Мәрҗанигә сүз бирик. «...Россиялеләр Казанга һљҗүм иткәндә,— дип яза галим,— ул, үзенең иярченнәрен җыеп, мәдрәсәгә керә һәм, мәдрәсә түбәсенә чыгып, россиялеләр белән бик каты сугыша. Руслар аны мәдрәсә (бу мәчет-мәдрәсәне шул чорда ук Кол Шәриф исеме белән йљртәләр) түбәсеннән чәнчеп тљшерәләр, һәм ул, шулай итеп, шәһит була...»[24]. Кол Шәриф һәм аның янындагы башка татар укымышлыларының батырларча һәлак булуын бу күренешләрнең шаһиты князь А.Курбский

да билгеләп китәргә мәҗбүр була. Шулай итеп, 1552 елның 2 октябрендә ил белән бергә аның рухи остазы Кол Шәрифнең дә гомере киселә. Бу олуг изге затның соңгы сәгатьләрен Әхмәт Рәшит[25] менә ничек тасвирлый:

Бераз тынып торган сугыш кинәт
Дљрләп китте тагы да кљчлерәк.
Ә Колшәриф — алтмыш тутырган карт,
Бетмәс икән кљч бу җанда да...
Телдә — Коръән сүзе...
Кулда — кылыч,
Менә кем ул илдә карчыга!
Ак фәрештә сыман ак киенгән,
Кайда кыен — шунда ашыга...
...Кинәт кемдер арттан, искәрмәстән,
Гљрзи белән орды җилкәне...

Кол Шәриф — күренекле рухани, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, үз халкының фидакяр заты гына түгел, билгеле шагыйрь дә. Әмма, кызганыч ки, аның бик аз әсәрләре генә сакланып калган. Татарлар арасында гаять киң таралган, Октябрь инкыйлабына кадәр Казанда күп мәртәбәләр нәшер ителгән «Бакырган китабы» үзенең тљзелеше белән хрестоматияне хәтерләтә. Анда, Сљләйман Бакыргани (Кол Сљләйман), Әхмәд Ясәви (Кол Әхмәд), Нәсими, Фәкыйри, Мискини, Икани һәм кайбер башка тљрки шагыйрьләрнең әсәрләре белән беррәттән, Кол Шәрифнең дә дүрт шигыре бар (барлыгы 35 бәет)[26]. Аларның барысы да тљзелешләре, тышкы формалары белән газәл жанрында. Әмма аларның берсен автор үзе «мљнәҗәт» дип атаган.

Кол Шәриф шигырьләре, Љмми Кәмал әсәрләре кебек, дини-суфичыл характерда. Аларда лирик каһарманның Алланы мактавы, аңа тартылуы гәүдәләнә. Автор үз укучыларын «гафләт» йокысыннан уянырга, күңелләрен пакьләргә, нәфескә бирелмәскә, Алланы һәрчак күңелдә тотарга чакыра. Шагыйрьнең аеруча «И күңел...» дип башланган газәле игътибарга лаек. Биредә автор кеше тормышының фанилыгын, әҗәлнең рәхимсезлеген, дљньяның һич «әүвәле», һич «ахыры» юклыгын аз сүзләр, гыйбрәтле сурәтләр ярдәмендә гаять оста итеп тасвирлый:

И күңел, бил баглама, күбне кичергән дљньядыр,
Бу үлем ширбәтен халыкка эчергән дљньядыр...
...Углыны атадин айрыб, кызны анадин тәкый,
Йыглатыб бер-бер ишекдә, зари кыйлган дљньядыр...

Гомумән, Кол Шәрифнең «Бакырган китабы»нда теркәлгән шигырьләре үзләренең поэтик тљзелеше, интонацион яңгырашы, сурәт-детальләргә бай булуы белән сыйфатланалар. Мљгаен, шуңадыр да алар укучылар тарафыннан яратып укыла, әдипләргә дә йогынты ясый. Кол Шәрифкә янә бер әсәр нисбәт ителә. Ул 1899 елда Казанда аерым китап рәвешендә басыла. «Кыйссаи Хљбби Хуҗа» дип исемләнгән бу дастанның тљп каһарманнары тарихта билгеле затлар: Хәким ата Сљләйман, аның хатыны Ганбәр һәм уллары Хљбби Хуҗа. Әүвәл дастани планда Сљләйман һәм Ганбәр тасвирлана, аларның изге эшләре сурәтләнә («Айдин-кљндин йарукдыр икесенең эшләре»; «Айәт-хәдис аларның агзындагы сүзидер...»). Алга таба Хљбби Хуҗаның игелекле эш-гамәлләре, могҗизалары гәүдәләнә.

Кол Шәриф шигырьләренең «Бакырган китабы»на кертелүе, «Кыйссаи Хљбби Хуҗа»ның эчтәлеге — болар бар да суфичылыкның, Әхмәд Ясәви һәм Сљләйман Бакыргани тәгълиматының, әсәрләренең Идел-Урал буйларында, җљмләдән Казан ханлыгында киң таралуын күрсәтүче мљһим дәлил.

**Мљхәммәдъяр Мәхмүд Хаҗи углы.** Бу әдип хакында Ш.Абилов, М.Госманов, Р.Мостафин һәм хәзерге чорның кайбер башка галимнәре кызыклы гына мәкалә-хезмәтләр яздылар. Шагыйрьнең әсәрләре дәреслекләргә, антологиягә кертелгән, аерым китап булып та басылып чыккан[27]. Шуңа күрә без Мљхәммәдъяр, аның иҗаты хакында кайбер белешмәләр, фикер-күзәтүләр генә биреп китәргә уйлыйбыз.

Әдипнең туган елы якынча XV йљзнең азакларына нисбәт ителә. Аның тормышы Казан белән бәйләнешле. Рухани, хаҗи гаиләсеннән («Атамыз Мәхмүд догачы...»). Автор «Тљхфәи мәрдан» ахырында үз атының «Мәхмүд хаҗи углы фәкыйрь Мљхәммәдъяр» булуын, әсәрен «Казан шәһәрендә» язуын искәртә. Ике урында шагыйрь үзен «Ярмљхәммәд» дип тә атый. Әсәрләреннән бу әдипнең шактый укымышлы булуы, гарәп, фарсы, тљрки телләрен һәм әдәбиятларын яхшы белүе аңлашыла.

Мљхәммәдъяр 1542 елда иҗат ителгән «Нуры содур» поэмасында «Мљхәммәд Әмин хан каберендә» «мљҗавир» (сакчы, «күрше») булып торуын искәртә. Чыганаклар татар хљкемдарларының Кремль эчендәге махсус каберлектә күмелүен телгә алалар. Археологлар да бу фикерне раслый. Кырым мәмләкәтенең Бакчасарайдагы хан утарында хәзерге кљндә дә бу тљр каберләр бар.

Мљхәммәд Әмин (аның әтисе — Ибраһим хан; әнисе — Нурсолтан) — Казан дәүләте белән 25 елдан артык идарә иткән хан. Ул 1518 елның декабрендә вафат була. Бу кодрәтле ханның Кремль территориясендә күмелүе, аның кабере љстендә махсус мавзолей корылуы табигый һәм мантыйкка сыя торган күренеш.

Мљхәммәдъяр «Тљхфәи мәрдан» әсәрендә үзенең күп мәшәкатьләргә, авырлыкларга дучар булуын да язып китә. («Чикдем әмма рәнҗ вә мәшәкъкать бихисаб».)

Шагыйрь кайчан үлгән соң? Бу сорауга тљгәл җавап юк. Мљгаен, ул да, чордашы Кол Шәриф кебек, Казан ханлыгы белән бергә (бәлкем, бераз алданрактыр да) һәлак булгандыр. Әмма шагыйрь үзе үлсә дә, аның ялкынлы сүзләре, гуманистик әсәрләре исән калган. Бу, әлбәттә, зур бәхет.

Безгә Мљхәммәдъярның љч әсәре — «Тљхфәи мәрдан» («Егетләр бүләге», 1540), «Нуры содур» («Күңелләр нуры», 1542) поэмалары һәм «Нәсыйхәт» шигыре мәгълүм. Соңгысы (ул 24 бәеттән гыйбарәт) тәүге мәртәбә М.Ивановның хрестоматиясендә (1842) басылып чыккан. «Нәсыйхәт» шигыренең эчтәлеге символик характерда: бер былбыл «күңел багына» очып килә. Әмма анда караңгылык, «тикән» (тигәнәк), хәшәрәт...» Озак очып йљргәч, ниһаять, былбыл бер «рәйхан гљле» таба һәм аңа үзенең әр-теләкләрен белдерә: әгәр дә син, тикәннәрне бетереп, үз орлыгыңны чәчеп үстерсәң, бакча нурланыр, аның «иясе» дә сљйкемлегә әйләнер иде...

Әгәр сәндә булырса фәһме кямил,
Гљле сач ул багына, булма җаһил.
Багың эче булыр ахыр гљлестан,
Сәңа бу дидекем бел: ула дәстан.

«Нәсыйхәт»нең тљп мәгънәсе шунда: кеше үзенең күңелен пакь, нурлы, «туры юлда» тотарга, «нәмәхрәм»нәр белән мавыкмаска бурычлы.

Үзенең символик образлары (былбыл, баг...), суфичылык рухы белән «Нәсыйхәт» Шәрекънең Гаттар, Румый әсәрләренә аваздаш. Күңелне бакча белән тиңләве, Коръән сүзен тотарга чакыруы, лирик каһарманны бәндә, кол, «буш кул» дип битәрләве, түбәнсетүе белән бу шигырь Љмми Кәмал парчаларын да хәтерләтә.

Мљхәммәдъяр поэмалары үзләренең поэтик корылышлары (аларның һәр икесе дә тартмалы композицион жанрда), әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрне үзәккә куюлары, лиро-эпик табигатьләре белән берберсенә охшаш. Һәр икесендә дә, куелган проблемаларга иллюстрация рәвешендә, тљрле шигъри хикәятләр китерелә. Хәтта сюжетлы љлешләрендә бердәй ситуацияләр дә очрый. Мәсәлән, «Тљхфәи мәрдан»дагы «Җеп эрләп сатучы ир белән хатын» һәм «Нуры содур» поэмасындагы «Хәммал» хикәятләре — әнә шундыйлардан. Аларның һәр икесендә дә тљп каһарманнар (гап-гади кешеләр) бурычын түли алмыйча авыр хәлдә калган затларны актык акчаларын биреп йолып калалар. Икенче кљнне берсе җебен, икенчесе утынын балыкка алыштыра: кайтып, балыкны ярып карасалар, аның эчендә — кыйммәтле энҗе! Хикәятләрнең мәгънәсе: игелекле эш-гамәлләр һич тә юкка чыкмый, артыгы белән үзеңә кайта.

Поэмалардагы хикәят сюжетларын автор тљрле чыганаклардан алган. Мәсәлән, Заһид турындагы сюжет генетик яктан «Кәлилә вә Димнә»гә һәм аның аркылы борынгы Һиндстан ядкәре «Панчатантра»га барып тоташа[28]. Мљхәммәдъяр поэмаларында Гаттар, Сәгъди әсәрләре, «1001 кичә» һәм Шәрекънең кайбер башка ядкәрләре белән уртак сюжетлар да бар. Әмма Казан әдибе алынма материалларны теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртә, аларны үзенең иҗади максатларына яраклаштырып эшкәртә. Нәтиҗәдә оригиналь яңгырашлы, мљстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган композицион берәмлекләр барлыкка килгән.

Мљхәммәдъяр поэмалары, гәрчә алар үзләренең идея-эстетик табигатьләре белән традицион характерда булсалар да, үз чоры љчен дә гаять актуаль яңгырыйлар. Билгеле булганча, 30 — 40 нчы еллар — Казан мәмләкәтенең авыр, каршылыклы чоры. Илнең эчке һәм тышкы сәяси, иҗтимагый тормышын яхшы белгән Мљхәммәдъяр, нәкъ Кол Шәриф кебек, дәүләтнең бљтенлеген, иминлеген саклау хакында уйлана, үз иҗаты белән тормышның зарури ихтыяҗларына җавап бирергә омтыла.

Үзенең бљек остазлары Йосыф Баласагунлы, Кол Гали, Котб кебек, Казан шагыйре дә илнең имин, бәхетле тормышын мәгърифәтле, гадел хљкемдарга бәйләп карый. Автор фикеренчә, «Падишаһ бер дәм» (мизгел) «гадел кыйлса», «ил-улус»ка ирек, рәхәтлек килер. Мондый хљкемдар вакытында җәмгыятьтә шундый социаль гармония урнашыр ки, хәтта «Бүре берлә куй бергә су эчәр, Үрдәк берлә карчыга бергә очар». Мљхәммәдъяр идеаль хљкемдар образын аеруча Нәүширван турындагы хикәятендә тулы гәүдәләндерә. Ни љчен бу патша вакытында ил тљзек («мәгъмур»), бай, бәхетле була? Чљнки Нәүширван укымышлы, гадел («Гадел берлә тотды дљньяны камуг, Тынды гадле берлә кечек һәм олуг»). Љстәвенә ул һәр эшен акыллы 70 вәзире белән киңәшеп башкара.

Безнең уебызча, «Нуры содур» әсәренең Кырым хъкемдары Сәхибгәрәйгә багышлануы да очраклы күренеш түгел. Ни љчен? Беренчедән, Сәхибгәрәй, туганы Мљхәммәд Әмин үлгәннән соң, Казан белән идарә иткән зат. Икенчедән, Сафагәрәй һәр ике очракта да туганы Сәхибгәрәй ярдәмендә тәхеткә утыра. Љченчедән, Кырым дәүләте — бу вакытта татар мәмләкәтләре арасында иң куәтлесе. Мљгаен, Мљхәммәдъяр, Сафагәрәй хакимиятенең кљчсезлеген, илдә тәртип, иминлек урнаштыра алмаячагын күреп, Сәхибгәрәйгә, киң татар җәмәгатьчелегенә мљрәҗәгать иткәндер, мәмләкәтнең һәлакәт упкыны алдында торуы хакында чаң суккандыр?! Автор үзен «дәрвиш, мескен» дип атый, «урдуга» (бу очракта «хан сарае» мәгънәсендә) «бармакка» мљмкинлеге югын әйтә. Болар да Мљхәммәдъярның Сафагәрәй хакимиятеннән читтәрәк торуына ишарә ясый.

Шагыйрь фикеренчә, илне, җәмгыятьне тљзек, имин, бәхетле итүнең мљһим бер шарты — кешеләр арасында табигый, гуманистик мљнәсәбәтләрнең булуы. Автор үзара ызгыш-талашларны кискен гаепли. Әдип, зирәк һәм тәҗрибәле остаз кебек, гаделлек, рәхим-шәфкать, юмартлык, сабырлык, тугрылык кебек күркәм гуманистик сыйфатларның асылын турыдан-туры да, тљрле сюжетлар мисалында да үз укучыларына җиткерергә омтыла, шулар ярдәмендә җәмгыятьне эчке яктан пакьләргә, камилләштерергә тели.

Љмми Кәмал, Кол Шәриф иҗатлары белән янәшә куйганда, Мљхәммәдъяр әсәрләренең тел-стиле чагыштырмача гади, аңлаешлы. Анда реаль тормыш белән кызыксыну, тарихи чынбарлык белән бәйләнеш кљчлерәк. Бу традицияне алга таба Мәүла Колый, Габди кебек шагыйрьләр дәвам иттерә.

Гуманистик рухлы, дљньяви эчтәлекле Мљхәммәдъяр поэмалары — күп гасырлык татар әдәбиятының үзенчәлекле бер сәхифәсе. Хәзерге кљн ихтыяҗлары шагыйрь иҗатын чагыштырма-тарихи планда комплекслы итеп тагын да ныграк, тирәнрәк тикшерүне кљтә.

***

Без, нигездә, Казан ханлыгы чоры, ягъни XV — XVI йљзләрдәге татар мәмләкәтләренең язма мәдәнияте хакында сүз алып бардык. Игътибар үзәгендә әдәби әсәрләр торды. Бу дәвернең күп кенә рухи истәлекләре юкка чыккан, бер љлеше, бәлкем, үзен табучыларны кљтеп, билгесезлектә кала киләдер. Безгә аеруча Себер, Әстерхан, Кырым мәмләкәтләренең язма истәлекләре юньләп билгеле түгел. Фәнгә мәгълүм ядкәрләрнең дә әле кайберләре бу мәкаләдән читтә калды. Мәсәлән, һәм татар дәүләтләрендә, һәм Мисыр мәмлүкләрендә әдәбият, нигездә, Алтын Урда мәдәни традицияләренә таянып үсә. Шуңа күрә XVI гасыр башларында Мисырда язылган «Тљрки Шаһнамә»се дә билгеле бер дәрәҗәдә татар мәмләкәтләрендәге әдәбиятка мљнәсәбәттә тикшерелергә тиеш. Әмма, кызганыч ки, биредә без ул мәсьәләгә туктала алмадык.

